Ситуация на рынке перевозок к этому времени кардинально изменилась. Испытанные годами транспортные компании разваливались одна за другой под натиском серых перевозчиков, постоянного роста цен на энергоносители и из-за ослабшей господдержки, которая перестала компенсировать расходы по тарифам, установленным ниже себестоимости перевозок.

Короче, Галиахметов снова попал в ситуацию под названием «И вновь продолжается бой!». Ключевое слово здесь – «вновь», ибо опытный боец опять вступил в состязание с внешними обстоятельствами за место своего ПАТП-1 под солнцем. Чтобы компенсировать названные выше, а также другие расходы, предприятие стало активно заниматься неосновной деятельностью: организовало платную стоянку, автомойку, услуги по ремонту автотранспорта и техническому обслуживанию населения, сдало в аренду свободные площади. Был включен режим жесткой экономии энергоресурсов, в соответствии с которым 50 автобусов перевели на газомоторное топливо, ввели в эксплуатацию свою газовую модульную котельную и водонапорную башню с артезианской скважиной. В компании изыскивались возможности для стабильного выплачивания зарплаты, пополнения автопарка и сохранения количества маршрутов.

Уже в 2003 году ОАО «Нижнекамское ПАТП-1» признали лучшим предприятием автомобильного транспорта в республике, а его руководитель в 2001 и 2004 годах становился победителем и лауреатом городских конкурсов «Человек – золотое сердце» в номинации «Добрые дела». По итогам 2005-го он был номинантом Республиканского общественного конкурса «Руководитель года». А по данным социологических опросов, 96% населения города и района были довольны деятельностью ОАО «ПАТП-1».

Несмотря на это, Агтас Нургатиевич выступил инициатором обращения транспортников к руководству РТ. В письме, подписанном директорами транспортных предприятий Нижнекамска, Альметьевска и Набережных Челнов, говорилось о серьезных проблемах, которые накопились в отрасли.

Высокая репутация ПАТП-1 позволила его работникам участвовать в транспортном обслуживании таких мероприятий регионального, российского и международного уровня, как чемпионат мира по хоккею с мячом (2005), 1000-летие Казани (2005), совещание Европейского банка реконструкции и развития (2007), спортивный форум «Россия – спортивная держава» (2009) и XXVII Всемирная летняя Универсиада (2013).

В 2014 году наш герой уступил должность генерального директора своему младшему сыну Марату, начавшему карьеру на этом предприятии в 2001 году и поработавшему начальником авторемонтных мастерских, затем главным инженером, а последние 10 лет – первым заместителем генерального директора. А Агтас Нургатиевич опять возглавил совет директоров ПАТП-1.

Ведомое дуэтом Галиахметовых АО «Нижнекамское ПАТП-1» считается одним из передовых автопредприятий как республиканского, так и всероссийского уровня. Оно активно занимается обновлением автобусного парка, модернизацией и укреплением сервисной базы, компьютеризацией технологических процессов и расширением сферы оказываемых услуг. Продолжается и практика обслуживания крупнейших мировых мероприятий, проходящих в Казани.

Это АО первым среди пассажирских автопредприятий было награждено дипломом лауреата конкурса «Лучшие товары Республики Татарстан» в номинации «Услуги», а затем стало обладателем диплома конкурса «100 лучших товаров России». В его портфолио есть дипломы лауреата национальной общественной премии транспортной отрасли России «Золотая колесница», «Лучшее предприятие Российского автотранспортного союза», «За вклад в развитие и улучшение благосостояния России», «Добросовестный перевозчик пассажиров». Упомянем еще диплом национального реестра «Ведущие организации транспорта Рос-

сии». Что касается полученных грамот и благодарственных писем, то перечислить их нереально.

А список личных наград нашего героя еще более впечатляющ: ордена, медали, знаки, почетные звания, и всего их более 30. Главное же богатство Агтаса абый – это крепкая семья: супруга, с которой муж отметил золотую свадьбу летом минувшего года, два сына и пять внуков. Роза Ахтямовна тоже была связана с нижнекамской промышленностью. Начинала электрослесарем на одном из заводов НКНХ, а после окончания вуза в Казани трудилась инженером в Нижнекамском монтажном управлении. «Я всегда восхищался ее старательностью и выдержкой, гордился ею», – говорит Агтас абый.



*Обложка книги А.Н. Галиахметова*

А их дети гордятся обоими родителями и благодарны им за ненавязчивые уроки жизни, теплоходные поездки в детстве и достойные семейные будни. Азату, отработавшему 10 лет замминистра, потом девять лет – заместителем генерального директора АНО «Исполнительная дирекция спортивных проектов», а в январе 2020 года назначенному начальником хозяйственного управления Кабмина РТ, запомнились слова отца о том, что нужно уметь делать все, в том числе и самую грязную работу, и ценить всех, кто рядом. А Марат, ставший в 2017 году третьим в семье заслуженным работником транспорта Республики Татарстан, на примере папы понял, что жить и работать надо с чистой душой и не отрываться от земли. Согласитесь, уважаемый читатель, выводы-установки, взятые сыновьями в жизнь, просты, но далеко не всем в обществе они служат маяком. У Галиахметовых – служат.

Это относится и к брату с сестрой Агтаса абый, тоже ставшим татарстанцами. Кадрия ханум была бухгалтером, а сейчас она на пенсии и проживает в Нижнекамске. А Атлас Нургатаевич (свой вариант отчества) работал на руководящих должностях в двух совхозах, потом – председателем колхоза и после этого 22 года возглавлял Управление сельского хозяйства и продовольствия в Заинском муниципальном районе. В начале 2019 года его – почетного гражданина этого района, почетного работника агропромышленного комплекса России и заслуженного работника сельского хозяйства РТ – проводили на заслуженный отдых.

Давно уже Агтас Нургатиевич перевыполнил известный минимум мужчины – построить дом, посадить дерево, вырастить сына. У увлеченного садовода есть и другое хобби – охота. Часто его можно встретить в школах, куда почетного гражданина Нижнекамска приглашают для встреч с учениками. Не забывает он и малую родину, приезжая в Камышлу пообщаться с родственниками и знакомыми, а также оказывая помощь мечети. Когда весной 2019 года в Интернете появилось сообщение о вручении А.Н. Галиахметову ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан», «всемирная паутина» откликнулась на это массой добрых слов и пожеланий в его адрес. Вот только парочка из них: «Человек-легенда, полвека отдавший нашему городу!», «Побольше бы таких неравнодушных, преданных своему делу людей!!!».

В упомянутой выше песне А. Пахмутовой есть такие строчки: «Человек оставляет людям / Песни, книги и города». А ведь они про Агтаса эфенди! Он строил юный город, и современный облик столицы нефтехимии Татарстана – это заслуга и нашего героя. Он возвел «Ильинку», где ежегодно поют песни. Он в конце 2020 года издал свою упомянутую выше книгу о прожитом и пережитом.

Знающие ее автора люди подчеркивают, что он обладает каким-то несгибаемым моральным стержнем, не допускающим периодов застоя в жизни. Стало быть, найдутся новые точки роста, которые Агтас абый возжелает превратить в круги новшеств. Что это будет, в какой сфере и в каком масштабе – мы не знаем. Возможно, наш герой решит чем-то порадовать Нижнекамск, готовящийся к своему 55-летию. Или родной Камышлинский район, 30-летие воссоздания которого отмечается в том же 2021 году. Но в любом случае – очередных успехов Агтасу Нургатиевичу!


*При вручении президентом РТ Р.Н. Миннихановым ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан», 2019 год*


Нурзидә Фәйзуллина

# ҺӘРВАКЫТТА ДА УКЫТУЧЫ АПА БУЛЫП КАЛАЧАК!

***Самарның “Яктылык” мәктәбендә күп еллар татар теле һәм әдәбиятын укыткан югары категорияле ветаран мөгаллим, Татарстанның атказанган укытучысы Әхмәтзыя кызы Нурзидә Фәйзуллина 2020 елда “Тәрбия һәм белем бирү өлкәсендә Россия Федерациясенең Мактаулы хезмәткәре” исеменә ия булды.***

**Миләүшә ГАЗИМОВА**

Күптән түгел лаеклы ялга чыкса да, гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган мөгаллимәнең йөрәге барыбер укучылары белән бергә кала ул.

Нурзидә апа кешеләрне тиз арада үзенә җәлеп итүе белән аерылып тора. Аның нурлы күзләре, эчкерсез елмаюы, гыйлемле булуы тирәюнендәгеләргә тирән тәэсир ясый. Милләттәшебез белән танышкач, аның якты образын күңел түренә салып куясың.

Әйе, чыннан да, аны күпләр ярата. Ә бар кешегә дә беркайчан да ярап бетеп булмый. Иң мөһиме – укытучы апа буларак, аны укучылары ярата.

Тормышта күзәтелгән нәрсә: кечкенәдән нужа күреп үскән һәм күп авырлыклар кичергән кешеләр гадәттә миһербанлы, гадел, кешелекле, саф күңелле, башкаларга карата ихтирамлы булалар.

Нурзидә апа белән аның узган гомере турында сөйләшеп утыргач, бу ханымның да ни өчен шушындый сыйфатларга ия булуына төшендем. Ул кичергән авырлыклардан биек тау өелер иде. Әтисез калу, матди яктан авырлыклар кичерү, якын кешесенең аның җметләрен акламау...

Нурзидә ханымның дөньяга килгән җире – Нальчик шәһәре. Аның этисе Әхмәтзыя – Башкортостан татары. 1950нче еллар башында Нальчикта хәрби хезмәттә була. Һәм аннан соң биредә яшәп кала. Нурзидә апаның эти-әнисе нәкъ шушы шәһәрдә танышалар да инде.

Әнисе һәм этисенең назын бертигез тоеп үскән бала – бәхетле бала. Тик менә Нурзидәгә этисенең итәгенә утырып назлану түгел, “эти” сүзен әйтергә дә насыйп булмый, чөнки, кызганычка, матур гына башланып киткән гаилә тормышы ирнең хыянәте аркасында чәлпәрәмә килә. Кызына 4 яшь тулгач, язмыш әнисе Зәмзәмияне чыгышы белән Татарстанның Апас районы Дәвеш авылы кешесе – Нәгыймулла исемле ир-ат белән кавыштыра. Шулай Нурзидә, үги булса да, этиле була.

50нче еллар уртасында Нурзидәнең гаиләсе Түбән Норлатка кайтып төпләнә. Шәһәрдә туып-үсеп, рус балалар бакчасына йөргән кызчык татарча бер генә сүз дә белми. Түбән Норлат мәктәбенә укырга кергәч, укытучыга аның белән гел русча сөйләшергә туры килә. Ә тора-бара Нурзидә, киресенчә, рус телен бөтенләй онытып, татарча гына сөйләшә башлый.

Беренче сыйныфта укыган 45 бала арасында кыз иң яхшы укучы була. Шуның өчен Нурзидәнең фотосурәте Мактау тактасында эленеп тора.

Нурзидә апа, әнисенә охшап, матур итеп җырлый. Әнисе аңа татарча да, урысча да бик күп җырлар өйрәтә.

Сигезенче сыйныфтан соң, кыз



Арча педагогия училищесына укырга керә. Аны шунда ук комсомолларның җитәкчесе итеп сайлап куялар. Бирегә Нурзидә пионервожатый һәм башлангыч сыйныфлар укытучысы булырга әзерләнә.

Шунысы да игътибарга лаек – училищеда милләттәшебезне татар теленнән якташларыбыз – Камышлы районының Байтуган авылыннан чыккан танылган шәхесләр, "Әлифба"ны төзегән ирле-хатынлы Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитова укыталар.

Педучилищеда авылларда белем бирәчәк студентларны универсаль укытучылар итеп әзерлиләр. Алар, төп фәннәрдән башка, шулай ук физкультураны да, музыка дәресләрен дә укытырга тиеш булалар. Шуңа күрә аларны музыка коралларында уйнарга да өйрәтәләр. Укырга кергәндә матур итеп җырлап күрсәткән моңлы тавышлы Нурзидәне скрипкада уйнаучылар классына билгелиләр. Тик кыз укытучыга бу уен коралында уйнарга теләмәвен белдерә. Тегесе моның сәбәбен сорагач, ул: "Безнең авыл клубында скрипка юк, баян гына бар, шуңа күрә минем шушы музыка коралында уйнарга өйрәнәсем килә", – дип җавап бирә. Шуннан соң аны танылган җырчы Айдар Фәйзерахмановның олы абыйсы – Марсель Фәйзерахманов алып барган баян классына күчерәләр.

Актив, тиктормас кеше буларак, педучилищеда Нурзидә хорга да йөри, төрле чараларда да катнаша. Аларның хоры, Казанда чыгыш ясап, беренче урын ала. Студентларны хәтта телевидениегә дә чакыралар.

Пионервожатыйга укыган кеше учак яга, палатка куя белмәсә, нинди пинервожатый була ди инде?! Шуңа күрә Нурзидәләрне икенче курстан соң озын-озак походка алып китәләр. Урманда аларны учак ягарга, ботка, аш пешерергә, палатка куярга өйрәтәләр. Хәтта төнлә урманда студентлар, үз курсташларының йокыларын саклап, чиратлашып кизү дә (дежурство) торалар!

Арча педучилищесын тәмамлагач, Нурзидә, читтән торып, Казан дәүләт педагогия институтына укырга кереп, татар мәктәпләрендә рус теле укытучысы һөнәрен үзләштерә башлый һәм Түбән Норлат авылында рус телен һәм музыка дәресләрен укытуга керешә.

1975 елда ул авылдашына кияүгә чыга, һәм алар Куйбышев шәһәренә күчеп киләләр.

"Бирегә миңа эшкә урнашуы авыр булды. Татар мәктәбе юк иде, рус мәктәбенә укытырга барырга курыктым. Шуңа күрә алдан заводка гади эшче булып урнашырга туры килде", – дип сөйли Нурзидә ханым.

Заводта бер ел эшләгәч, ул вакытта өлкә укытучыларының белемен камилләштерү институты белгече Минзакир абый Нуретдинов ярдәме белән ул балалар бакчасында тәрбияче булып эшли башлый һәм шушы дәвердә педагогия институтын бик яхшы билгеләргә генә тәмамлый.

Тормышы шулай әкрен генә җайланып китә аның. Ире фатир ала. Нурзидә дә өйләре янында урнашкан балалар бакчасына күчә. Кызлары Резеда туа. Ул да бүген Самарда үз тормышы белән яши.

Декрет ялыннан соң Тарасов исемендәге заводның (КАТЭК) балалар бакчасына эшкә урнашкан Нурзидә ханым ул вакыттагы бер вакыйганы исенә төшерде.

Бервакыт татар концертына баргач, Нурзидә апа Минзакир абый Нуретдиновны очрата. Ул аны Хәридә Дашкина һәм Асия Сәйфетдинова белән таныштыра. Бу












1993 елның сентябрь башлары була. Шунда Минзакир әфәнде Нурзидә Әхмәтовнага, бер кечкенә мәктәп нигезендә татар бүлеге ачылуын хәбәр итеп, аңа анда татар телен укытырга тәкъдим итә. Шулай язмабыз герое Самарның 12нче кичке мәктәбе каршында ике сыйныфтан торган татар бүлегендә укыта башлый.

Тора-бара кичке мәктәптә тагын берничә сыйныф ачыла, татар бүлеге киңәя бара. Бергә укытучылар – Гөлчәчәк Нуруллина (завуч та булып эшли), Гөлҗиһан Мәхмүтова, аннан Радик Газизов, Нурзидә апаның бертуган сеңелесе Фәридә Зиннәтуллина киләләр.

1997 елда Хәридә Дашкина тулы татар мәктәбен ачу турында сүз кузгата һәм укытучыларны балалар тупларга ярдәм итәргә сорый. Татар милли хәрәкәте активистлары – Шамил Баһаутдин, Әминә Шәмси һәм укытучылар, җиң сызганып, эшкә керешәләр. Татар фамилияләре язылган исемлек белән өйләр буенча йөреп, ата-аналарны балаларын татар мәктәбенә укырга бирергә өндиләр.

"Шулай ике катлы мәктәбебез ачылды. Хәридә апа аңа "Яктылык" дип исем бирде. Ул шушы исемне биргәндә Самарда яшәүче татар балаларының, яктылыкка омтылган кебек, ана телен өйрәнергә, татар милләтенә, татар тарихына, әдәбиятына, мәдәниятенә омтылуларын күздә тоткандыр, мөгаен. Харидә апа бу исемне дөрес кушкан", – ди Нурзидә Әхмәтовна.

Татар теле һәм әдәбиятыннан тыш, ул биредә якшәмбе мәктәбендә дә укыта. Татар телен, тарихын, мәдәниятен өйрәнергә теләүче төрле яшьтәге, төрле милләттәге кешеләргә белем бирә. Олысына да, кечесенә дә кызыклы, файдалы дәресләр үткәрер өчен бөтен мөмкинлекләрен кулланып эшли укытучы. Ә ул күп нәрсәләрне белә. Шуңа күрә аны шаярып: "аяклы энциклопедия", – дип атап йөртәләр.

Тормыш сәбәпләре аркасында ире белән аерылган Нурзидә ханым нәкъ якшәмбе мәктәбендә заманында Самарның төрле дәвалау учреждениеләрендә баш врач, психотерапевт булып эшләгән икенче ире Мәгъруф Гыйльмияров белән таныша да инде. Һәм күп еллар аның белән бәхетле гомер кичерә. Нурзидә апа ире турында сөйләгәндә: "Ул – минем яраткан, хөрмәт иткән, кадерле, якын кешем. Тәпле, акыллы, белемле ир, зур хәрефтән язарлык шәхес", – дип җылы сүзләр генә куллана.

Нурзидә Фәйзуллинаны укучылары да бик яраталар. Ул да аларны чын күңеленнән сөеп, үзләренә: "улым", "кызым", – дип эндәшә. Укытучы үз белемен даими рәвештә камилләштерә бара. Мәктәптә төрле бәйрәмнәр, чаралар да оештыра һәм аларны һәркем өчен кызыклы итеп үткәрергә тырыша.

Укытучы мәктәп тормышына чумып эшли. Балаларны олимпиадаларга, бәйгеләргә әзерли. Укучыларында шигырьләр, хикәяләр язарга сәләтләрен күреп-сизеп алгач, аларның бу талантын үстерү өчен бар көчен куя, ничек булса да үзләрен кызыксындырырга тырыша.

Нурзидә Фәйзуллинаның укучылары аның җитәкчелегендә проектлар әзерләп, башка төбәкләрдә узган фәнни конференцияләрдә еш кына җиңүче исемен алып кайталар, призлы урыннар яулыйлар.

Тынгысыз җан булган Нурзидә Әхмәтовна үз вакытында мәктәптә "Аргамак" дип аталган шигырь сөючеләр түгәрәгенә дә оештыра. Шигърият кичәләре үткәреп, балаларны татар теленең, әдәбиятының матурлыгын күрергә өйрәтә.

"Аргамак"ка йөргән укучым Наил Вәлиев мәктәпне тәмамлагач, 7 – 8 елдан соң очрашу кичәсенә килде. Шунда ул миңа: "Апа, Сез миндә татар әдәбиятына, татар шигъриятенә мәхәббәт уяттыгыз. Рәхмәт Сезгә", – диде. Әгәр дә мин укыткан 100 баланың берсендә генә булса да ана телебезгә мәхәббәт уята алганмын икән, димәк, юкка укытмаганмын булып чыга", – ди милләттәшебез.

Нурзидә Фәйзуллина дәресләрдә дә, алардан тыш чараларда да укучыларны бөек шәхесләребез, танылган якташ шагыйрьләребез, язучыларыбыз, композиторларыбыз белән таныштыра. Кызыклы, күңел түренә үтеп керерлек сценарийлар төзеп, балаларга татар теленең матурлыгын, моңлылыгын күрсәтеп, аларга карата соклану уята.

Нурзидә Фәйзуллина шәһәребезнең милли хәрәкәте эшләрендә дә бик актив катнаша, укучыларын да моңа җәлеп итә. Шулай ук шәһәребезнең "Сәлам", "Бердәмлек" газеталарына төрле темаларга мәкаләләр яза.

Укучыларының мәктәпне акыллы, тәртипле, белемле кешеләр булып тәмамлавы – укытучы өчен иң зур бүләк. Шулай ук югары органнар тарафыннан да хезмәтенә лаеклы бәя бирелүе дә – мөгаллимнең күңелен күтәрә торган күренеш, әлбәттә. Нурзидә апа үзенең бүләкләр санында Татарстан фән һәм мәгариф министрлыгының "Мәгарифтәге казанышлары өчен" күкрәк билгесен, Самар Губерна Думасы Мактаунамәсен, Самар шәһәре мәгариф департаментының,




Бөтендөнья татар конгрессының рәхмәт хатларын, Совет районының халык мәгарифе хезмәткәрләре профсоюз оешмасының Мактаунамәсен һәм башкаларны кадерләп саклый.

Ярдәмчел, юмарт, һәр кешенең яхшы якларын гына күрергә омтылган Нурзидә ханым Фәйзуллинаның хезмәте аның яшәү рәвеше, бәхет чыганагы булып торды. Мөгаллимә укучыларына биргән белеменә үзенең күңел җылысын, мәхәббәтен дә кушып укытты. Шуңа күрә, хәзер лаеклы ялга чыкса да, ул һәрвакытта да Укытучы апа булып калачак...

*Фәния Гыйләҗева*



# “КЕШЕ ЧИТТӘН СИНЕҢ ЯХШЫ СЫЙФАТЛАРЫҢНЫ КҮРЕП ШАТЛАНСА, БУ ИНДЕ ТОРМЫШТА - ЗУР ҖИҢҮ”

**Миләүшә ГАЗИМОВА**

***“Укытучы – оста артист, ләкин аңа кул чапмыйлар. Ул - оста скульптор, ләкин аны күрмиләр. Ул – яхшы табиб, ләкин аңа пациентлары бик сирәк кенә дәвалаган өчен рәхмәт әйтә, кайберәүләре кайвакыт дәваланырга да теләми.***
***Ә рухлану өчен кайдан көч алырга соң? Бары тик үзеңнән, үзеңнең хезмәтеңнең бөеклегеннән”.***

***С.Л. СОЛОВЕЙЧИК***

Укытучы – бөек җан ул. “Укытучы» сүзе – изге сүз ул. Һәр кеше, мәктәпне тәмамлап, еллар узган саен бу сүзнең тирән мәгънәсенә тагын да ныграк төшенә башлыйдыр. Мөгаллим, бөтен көчен биреп, укучыларын матур итеп үз фикерләрен җиткерергә, балалар күңеленә югары әхлаки орлыклар салырга тырыша, тормышны аңларга, аны яратырга өйрәтә, нарасыйларның уңышына чын күңелдән шатлана һәм алар белән горурлана.

Балаларга татар телен, туган телне өйрәтүче укытучыны бигрәк якын күрәм мин, чөнки бу – безнең милләтебез теле. Аны юкка гына назлы итеп “ана теле”, дип атамыйлардыр инде.

Нурсәхи кызы Фәния ханым Гыйләҗева – Самарның “Яктылык” мәктәбендәге шундый күркәм укытучыларның берсе. Ул укучыларга татар теле һәм әдәбияты буенча белем бирә.

Татарстанның атказанган укытучысы, Россия Федерациясе мәгарифенең мактаулы хезмәткәре, Россия күләмендә узган “Иң яхшы укытучы” бәйгесендә җиңеп, 100 мең сумга лаек булган Фәния ханым Гыйләҗева белән рәхәтләнеп ана телебездә сөйләшеп утырдык.

**– Фәния апа, кайсы якның чишмә суларын эчеп үстегез?**

– Кләүле (хәзер Камышлы) районында урнашкан Балыклы авылы чишмәләренең баллы суын эчеп, гүзәл табигате кочагында назланып үскән кыз мин.

**– Әти-әниегез сезгә нинди тәрбия бирделәр?**

– Без әни канаты астында гына үстек. Көз көне амбарда ашлык чистарткан вакытта әтиемне ток сугып үтерде. Шулай 38 яшьлек өрлектәй ир, хатынын, дүрт баласын, әнисен калдырып, мәңгелеккә күчте. Ул вакытта миңа өч яшь ярым иде. Әтине җирләргә алып киткәндә кул болгап озатып калганымны хәтерлим.

Әнием безне берүзе тәрбияләде. Олы апам 13 яшендә чирләп үлде. Ике энем белән үстек.

Әниебез башлангыч сыйныфлар укытучысы иде, өстәмә хезмәт дәресләрен алып барды һәм китапханәдә эшләде. Шулай аннанмоннан акча табып, газиз балаларын башкалардан ким булмыйча үстерергә тырышты, мәрхүмкәем. Аннары татар телен дә укытты.

Әниебез тормышта безнең өчен маяк иде. Уч төбендә сикертеп үстермәсә дә, безне ачуланганы да, кул күтәргәне дә булмады. Без хезмәт белән тәрбияләнеп үстек. Энеләрем йорт эшләрен башкардылар, мине сарайга чыгармадылар, тирес түктермәделәр. Мин өйдә хатын-кыз эшләре белән мәшгуль булдым. Әни мәктәптән кайтканчы барысын да өлгертеп куя идек.

Кичләрен өстәл тирәсенә барыбыз бергә җыелып, тәмле ашлар ашап, матур гына сөйләшеп утыру гадәтебез булды. Әни хәлләребезне, нинди билгеләр алганыбызны сораша. Шундый ямьле, күңелле чаклар!

Әниемнән бөкри, мантый, җәймә, кыстыбый, пәрәмәч пешерү осталыгына өйрәнеп калдым. Бигрәк тә яңгырлы көннәрдә мунча ягып, таба ашлары белән сыйлый иде ул безне. Кунаклар килгәч, без олылар белән бергә табынга утырмадык.

Анамның бер исткиткеч ягы белән әле һаман да сокланам – ул татар халык мәкальләрендә балыктай йөзә иде. Шулкадәр күп мәкальләрне ничек исендә тота алгандыр инде! Халык сүзе шулхәтле хак бит ул, аңарда хикмәт бар, бер мәкаль үзенә бер романны тәшкил итә. Мин укучыларыма да: “Балалар, татар халык мәкальләрен күбрәк белсәгез, тормыш үзеннән-үзе ямьләнеп китә. Сезнең белән аралашучы иптәшләрегез сезгә артык бер сүз әйтә алмый торган була, бер генә мәкаль белән сез аларны урыннарына

куя аласыз. Җавабыгыз төгәл дә, дөрес тә, аңлаешлы да була", – дип әйтәм.

Әнием халык сүзен гел сөйләмендә кулланды. Аның янына кайткач, бер генә мәкален отып калсам да, миңа яшәргә ничектер җиңелрәк булып китә иде.

Әниебез бик уңган, җитез, эшчән, чиста хатын булды. Безне дә үз үрнәгендә тәрбияләде. Тыйнак, матур кеше иде ул. Шул ук вакытта тапкыр телле, үҗәтле, тиз фикер дә йөртә белде. Бервакытта да үзенең исемен таптатырга бирмәде. Шушы мәкальләре, үз-үзен тота белүе ярдәм иткәндер инде.

Безне ул приказ биреп түгел, йомшак сүз белән, юхалап, мактап, "Ии, кызым, булдыргансың икән", "Ии, улым, яныкаем, тыңлыйсың да бит", дип эшләтә иде. Җаен дә, сүзен дә таба белде. Өчебезне дә югары белемле итте, өчебезнең дә туйларын уйнады.

Матур җырлый, бәйрәмнәрне алып бара иде. Әнием турында горурланып кына искә алам мин.

**– Әниегез эзеннән китеп, укытучы һөнәрен сайларга булдыгызмы әллә?**

– Әнием үрнәге дә этәргеч булды. Беренче укытучым Фәһимә апа Гаделшинаның дәресләрен дә бик яраттым. Журнал ясап, балаларның исем-фамилияләрен язып, үзләренә билгеләр куеп, укытучы булып уйный идем.

Мәктәптән соң Алабуга институтына филология факультетына укырга кердем. Икенче курста үземне староста итеп куйдылар. Уку җиңел бирелде миңа. Урыс, татар телләре һәм әдәбияты укытучысы булып чыктым.

Аннары юллама буенча Кләүле районының Никиткино исемле чуваш авылына эшкә җибәрделәр. Ике ел эчендә өстәмә немец телен дә, географияне дә укыттым. Әнием дә берничә ел географияне укыткан иде. Аның сакланып калган язмалары, планнары, китаплары миңа бик ярап куйды.

1985 елда Иске Усман авылының Рәшит исемле егетенә кияүгә чыгып, шунда эшли башладым. Алты ел тату гына гомер иткәч, 30 яшендә ирем вакытсыз якты дөньядан китеп барды.

1998 елда кыш уртасында, ике баламны ияртеп, Иске Усманнан Самарга чыгып киттем. "Яктылык" мәктәбенең беренче мөдире Хәридә ханым Дашкинага әле дә рәхмәтлемен, мине эшкә кабул итте. Башлангыч сыйныфларда рус телен укыттым, дәресләрдән соң, әти-әниләре килеп алганчы, балалар белән шөгыльләндем. Менә "Яктылык"та эшләвемә 23 ел булды инде. Гомер тиз уза шул.

**– Укытучы хезмәте күңелегезгә нәрсәсе белән якын**?

– Балаларны яратам мин. Аларны сөймәсәң, мәктәпкә якын да барырга түгел. Һәр дәрес - бер ачыш бит ул. Һәрберсе тормыш белән бәйле. Көн саен яңалыклар, нинди дә булса үзгәрешләр. Бер дәрес икенчесенә бер дә охшамаган. Мин бертөрлелекне яратмыйм. Параллель классларда бер үк дәресне төрлечә, кызыклы итеп бирергә тырышам. Укучыларның, күзгә карап, җавап биргәннәрен, аларның күзенә карап, дәресемне аңлатырга яратам. Балаларның яхшы укулары, мин биргән теманы аңлаулары, югары билгеләр алулары – барысы да күңелне бизи, әлбәттә.

**– Сез татар телен укытасыз. Балаларга ана телен үзләштерүе авырмы? Алар телне яратып өйрәнәләрме? Бер сүз дә татарча белмәүче нарасыйлар мәктәптә генә туган телне үзләштерә алалармы яисә гаиләдән башларга кирәкме?**

– Иң беренче чиратта, гаиләдән башларга! Мин мәктәптә төрле чараларда чыгыш ясаганда да сүземне түбәндәгечә башлыйм: "Хөрмәтле әти-әниләр, әби-бабайлар. Каникуллар вакыты җитә, балаларыгызны хезмәткә өйрәтегез. Һәм, зинһар өчен, үтенеп сорыйм – алар белән русча аралашмагыз, татарча сөйләшегез".

Бер елны олимпиадада да Казан мәгариф системасының бер вәкиле:

"Чегәннәрнең мәктәпләре бармы? Юк. Ә ничек соң алар үз телләрен яхшы беләләр?" – дип сөйләгән иде. Менә синең соравыңа җавап, Миләүшә, ул балалар ана телен гаиләдә өйрәнәләр, һәрвакыт үз телләрендә сөйләшәләр.

Саф татар гаиләсендә үскән нарасыйлар мәктәптә татар теле дәресләрен яхшы үзләштерәләр, олимпиадаларда катнашып, призлы урыннар яулыйлар. Ул балаларга да, аларның әти-әниләренә дә мин рәхмәтле. Кем өйдә татарча сөйләшә, аңа белем алуы ансат.

Укучыларның теләкләреннән дә күп нәрсә тора, әлбәттә. Күзләрендә очкын күрсәм, аларның тиз өйрәнәчәкләрен шунда ук сизеп алам. Тырышлыгы, теләге булмаганнарга, әлбәттә, телне үзләштерү авыр, алар кирәксенмиләр дә. Хәтта бер генә сүз дә татарча белмәгән балалар, теләкләре булса, яхшы укып китәләр.

Мин әби-бабайларына һәрвакыт: "Сезгә оныкларыгыз әби-бабай, дип эндәшәләр. Сез аларга шушы сорауны бирегез – ә үзләре картайгач, оныкларыннан әби-бабай, исәнме, саумы, хәлең ничек сүзләрен ишетерләрме? Оныкларыгызга шуны җиткерегез", – дип сөйлим.

**– Сез укыткан нарасыйларның күбесе татар теле буенча олимпиадаларда призлы урыннар алып килүен беләм. Бу – укытучының яхшы хезмәтенең күрсәткече, дип санийсызмы, баладан да күп нәрсә торамы?**





– Менә Айсылу Урсакаевадан башласам, ул, иң беренче булып, төбәкара олимпиадада катнашып, сәнгатьле тел һәм сөйләм өлкәсендә “Яктылык”ка уңыш китерде. Үҗәтлеге белән иреште ул моңа. Денис авылы кызы Алия Галиуллина шулай ук төбәкара олимпиадада өлкәбезгә җиңү китерде. Әлбәттә, укучыларның үзләреннән күп нәрсә тора. Тырыш балаларга исләрем китә минем - хаталарын төзәтәләр, эшләрен җиренә җиткереп башкаралар. Һәм, шатлыгыбызга, андыйлар күп. Укучыларыбызның уңышлары безнең эшебезнең күрсәткече дә булып тора, әлбәттә.

**– Балаларда туган телгә мәхәббәт тәрбияләр өчен нинди ысуллар кулланасыз?**

– Гәҗитә-журналлар, китаплар, матур әдәбият, кызыклы әсәрләр аша кызыксыну уятырга тырышабыз. Бездә эшләгән Сәгыйдә ханым Нурсәхиеваның ире такта башына элеп куярга төрле әйтемнәр язылган плакатлар ясаткан иде. Мәсәлән, анда Каюм Насыйринең “Рус телен өйрәнергә кирәк, үз телеңне белу тиеш”, дигән сүзләре дә урын алды. Шуны һәр дәрес алдыннан кабатлый идек.

Әкиятләр белән бәйләп, кызыклы диалоглар, монологлар төзибез. Төрле-төрле чаралар эзләп табабыз инде.

**– Дәресләрдән тыш, үз фәнегез буенча нинди чаралар уздырасыз?**

– Төрле әсәрләргә нигезләнеп сәхнәләштерелгән тамашалар оештырабыз. Бөек шагыйрьләребез һәм язучыларыбызның туган көннәренә багышланган кичәләр үткәрәбез. Шигърият бәйрәмнәрен дә балалар бик ярата. Укучыларыбыз өлкә күләмендәге “Мирас” фестивалендә, фәнни конференцияләрдә катнашалар.

**– Фәния апа, “Яктылык”та төрле милләт балалары укый. Программа таләп иткәнчә, алар да татар телен үзләштерергә тиеш. Моңа карата укучыларның һәм ата-аналарының мөнәсәбәтләре нинди, авырлыклар тумыймы?**

– Нинди авырлыклар! Алар әле күп татарлардан да ныграк яратып укыйлар. Ата-аналарының каршы килүе түгел, киресенчә, һәрвакыт хуплап, шатланып торалар. Кыргыз, үзбәк балалары, хәтта татар теле буенча олимпиадаларда катнышып, җиңүләргә ирешәләр. Мәсәлән, кыргыз кызы Айтурган Осмонова гел татар теле буенча олимпиадаларда уңышлы катнашып килә.

**– Сезнеңчә, укытучы, белемнән тыш, тәрбия дә бирүчеме яисә тәрбияне ата-ана бирергә тиеш, дип саныйсызмы?**

– Әлбәттә, тәрбияне күбесенчә әтиәни бирә. Хәзерге заманда бөтенесе дә телефонга чумган – шунысы аяныч. Балаларны тыңлатырга җиңел түгел. Әмма без, укытучылар, тырышабыз инде. Дәрестә дә, мәктәп чараларында да, тәнәфестә дә тәрбия темасын кузгатабыз.

**– Укытучы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

– Иң беренче – балаларны яратырга. Үзенә дә игътибарлы булырга тиеш.

Фәнис Яруллинның укытучылар турында “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” исемле матур шигыре бар. Аны җырга да салдылар. Юбилеем белән котлап, мәктәпне тәмамлаган укучым Зилә Минебаева, шушы җырны үзе башкарып, миңа видеосын җибәрде.

Анда шундый сүзләр бар – “...сез иң күркәм кеше икәнсез.., сез иң гүзәл кеше икәнсез.., сез иң сабыр кеше икәнсез...”

Аны тыңлаганда күз яшьләремне тыя алмадым. Мөгаллимдә шушы сыйфатларның барысы да булырга тиеш. Сабырлык кирәк. Чыдам булмасаң, нәтиҗәгә ирешә алмыйсың.

**– Ата-аналар белән мөнәсәбәтләрегез ничек?**

– Алларында да, артларында да бер үк сүзне сөйлим. Берсенең сүзен икенчесенә җиткермим. Җыелышларым да озын-озак уза минем, әти-әниләрнең тиз генә таралышасылары килми. Гел турыга, дөресен әйтәм. Начар мөнәсәбәттә булганыбыз юк. Миңа ата-аналар белән эшләргә җиңел. Дөресен әйткәнгә аңлыйлардыр инде.

**– Читтән торып укыту процессында нинди кыенлыклар белән очраштыгыз?**

– Интернетның тизлеге түбән булганга, вакытында кереп, тиешле 30 минутлык дәресне рәхәтләнеп бирә алмаган чаклар күп булды. Андый вакытларда WhatsApp, Viber аша аралашырга туры килде. Онлайн форматта бөтен укучылар да дәрескә керми. Аннан соң өйдә баланың игътибары барыбер түбәнрәк дәрәҗәдә була, читкә китә, өй мохитендә ялкаулык та баса бит инде.

Күрсәтмә әсбапларны, биремнәр әзерләү, өй эшләрен тикшерү буенча да техник авырлыклар барлыкка килде.

Шуннан соң, әйткәнемчә, баланың күзенә карап укытырга, аның җавабын күзенә карап алырга яратам мин. Шулай булмагач, бу – минем өчен зур кимчелек.

Үземнең дәресләремдә мондый ысулның бер яхшы ягын да күрмәдем. Сүз дә юк, барысын да җиренә җиткереп эшләүче балалар да булмады түгел. Бу инде күбрәк аларның үзләреннән тора.

**– “Яктылык”тагы хезмәтегез нәрсәсе белән күңелегезне бизи?**

– Укучы күңеленә кереп кала



*«Яктылык» мәктәбенең беренче директоры Хәридә Дашкина (сулда) һәм Фәния Гыйләҗева*

алсаң, минем өчен шул - шатлык. Әти-әниләрнең балаларын мәктәпкә якты йөз белән китереп бирүе, укучыларның татарча сөйләшүе, җыр җырлавы, шигырь сөйләве, куелган бурычларның, таләпләрнең үтәлүе, балаларның уңышлары, журналда үзләренә яхшы билгеләр кую, тирән белем бирү – шулар күңелемне бизи. Укучының күзенә карап, әйе, мин әзер дигән чаткыны күреп, тулы җавабын алсам, безнең эштән ата-аналар канәгать булса, ләззәт тоям.

**– Укытып чыгарган балаларыгызны сагынасызмы, аларның язмышлары белән кызыксынып яшисезме? Үзләре сезнең белән элемтәдә торамы?**

– Укучыларыма икенче әни булырга тырышам мин. Укудан тыш, тормыш проблемалары белән мөрәҗәгать итсәләр дә, киңәш сорасалар да, хәлемнән килгәнчә ярдәм итәм. Исемдә, бер елны депутат Александр Хинштейн Кремльдә чыгарылыш балына баруны оештырды. Анда укучым Ләйсән Мансуровага булып кайту бәхете татыды.

Ләйсән яныма килде дә: “Апа, барасым килми”, – ди. “Юк, барасың, Ләйсән, ул сиңа зур истәлек булып калачак. Андый мөмкинлек башка беркайчан да булмаячак”, – дип җибәрдем үзен Мәскәүгә. Ул әле дә моның өчен миңа рәхмәтләрен белдерә.

Мәрьям Батршина, Эльвира Йосыпова, Җәмилә Шәрифуллина, Камилә Сафиуллина, Алсу Хуҗина, Зилә Минебаева, һәрвакыт шалтыратып, хәлләремне белешеп, бәйрәмнәр белән котлыйлар, тормышларындагы мөһим вакыйгалары турында сөйлиләр. Калган укучыларым да онытмыйлар, рәхмәт барысына да. Социаль челтәрләрдә дә аралашып торабыз.

Ә менә тәртип бозучы балаларны аеруча юксынам. Алар бит, яхшы укучыларга караганда, күбрәк сагындыралар. Мәктәпне тәмамлаган укучым Галия Хәлиуллина да еш шалтырата. Бервакыт ул миңа: “Апа, Шамил сыйныфташым: “Әгәр Фәния апага эләкмәгән булсам, миннән кеше чыкмый иде”, дип әйтә”, – ди.

Шундый сүзләрне ишеткәч, яшисе килә бит! Баланың кыйбласын үзгәртеп, яхшы юлга басуына өлеш керттем икән, шушы бәхет түгелмени?!

Яхшы укучыларым уку өлкәсендә зур горурлык булса, тәртипсезләрнең безнең ярдәмебез белән дөрес кыйбла сайлаулары – тормышта зур горурлык.

**– Буш вакытларыгыз калса, нәрсә белән шөгыльләнергә яратасыз?**

– Иртәнге җиденче яртыда өйдән чыгып китәм, кичен сигезенче яртыда кайтып керәм. Буш вакытлар аз эләгә шул. Андый чакларда оныкларым белән күрешергә тырышам.

Балаларымны таба ашлары белән сыйлап үстердем. Татар ашларын әзерләргә ятатам. Шушы сыйфатым кызыма да күчкән, минекеннән дә тәмлерәк пешерә. Каенанасы да бик уңган, аңардан да күп нәрсәгә өйрәнә.

Социаль челтәрләрдә төркемдәш кызлар белән элемтәдә торабыз. Китаплар укырга, татар җырларын тыңларга яратам мин.

**– Гаиләгез турында да әйтеп үтсәгез иде.**

– Кызым Рания, улым Руслан. Дүрт онык әбисе мин. Гаиләмә тагын бер улым Илнар, кызым Елена өстәлде. Кияү белән киленемне үз балаларымдай кабул иттем. Эшчәннәр, уңганнар, акыллылар, Аллаһыга шөкер. Балаларым, оныкларым белән гел татарча сөйләшәбез.

**– Үз гомерегездә үкенгән чаклырыгыз булдымы?**

– Кеше язмышын үзеңә ала алмыйсың, үзеңнекен кешегә бирә алмыйсың. Аллаһы нәрсә язган – шуны үтәбез. Бервакытта да үкенгәнем булмады.

**– Тормышыгыздагы иң мөһим, истә калган вакыйгалар нинди?**





*Фәния Гыйләҗева (уңнан икенче), энеләре Фәиз, Фәнис, киленнәре Рәсимә, Гөлфирә белән*

– Әнинең җылы куенында үскән балачагым гел истә. Олыгая барган саен кечкенә чаклар ныграк сагындыра икән ул. Әле дә туып-үскән йортыбызда карлыган-чияләр, алмагачлар мул уңыш бирә. Яз көне туган нигезебез шау чәчәктә. Кайткач, шушы куак, агачлар арасыннан нурлы йөзле әниебез килеп чыгар кебек. Балачак хатирәләре гомерлеккә истә кала шул ул.

Балаларымның тууы, аларны башлы-күзле итү, оныкларымның дөньяга килүе – зур бәхет китергән олуг вакыйгалар.

Өч педколлективта эшләдем, өчесе дә берсеннән-берсе әйбәт булдылар. Бер коллективта да укытучыларның үзара сүзгә килешмәгәннәрен күрмәдем. Бер мәктәптә дә миңа начар директор эләкмәде, җитәкче буларак, һәрвакыт ярдәм итеп, юл күрсәтеп, хуплап тордылар.

Студент еллары да, безгә тирән белем биргән көчле укытучыларым да якты истәлек булып калды.

**– Тормышта кемнәргә таянып яшисез?**

– Аллаһы Тәгаләгә таянам. Балаларым, энеләрем Фәнис, Фәиз – ышанычлы терәгем. Энеләрем гомер буе ике канатым булдылар, мине, апа буларак, зурлап, булышып яшиләр. Бәхетемә, аларның хатыннары – Рәсимә һәм Гөлфирә дә – бик яхшы кешеләр. 30 елдан артык аралашып, дус гомер итәбез. Мин дә ике балам белән калдым, Фәиз хатынының апасы да ике бала белән калды. Алар шушы нарасыйларны да кайгыртып яшәделәр бит әле.

Балаларыма да: "Сез шуларны күреп үстегез. Беркайчан да туганлык җепләрен өзмәгез", – дип әйтеп киләм. Газиз нарасыйлары башлы-күзле булып, энеләремә дә оныклар бәхетен татырга насыйп булсын.

**– Фәния ханым, 60 яшьлек юбилеегызны билгеләп үттегез. Бу, артка борылып карап, тормышыгызга берникадәр нәтиҗәләр ясау мөмкинлеге дә, алга карап, киләчәккә ниятләр күзаллау вакыты да. Сез нинди нәтиҗәләр ясый аласыз һәм киләчәктән нәрсәләр көтәсез? Гомумән, узган елларыгызны бәхетле тормыш, дип тасвирлый аласызмы?**

– Әнием миңа туемда: "Көчле рухлылар гына максатына ирешә", – дип әйткән иде. Әйе, тормышта кайгылар да кичердем, бәхетле чакларым да булды. Һәрхәлдә дә, Коръән кушканча, сабыр булырга тырыштым. Кайгысына гына түгел, җырчы Хәния Фәрхи, бәхеткә түзеп кара, дип, җырлаганча, анысына да түзә белергә кирәк бит ул. Артык шатланмаска - бәхет артыннан хәсрәт килә, артык кайгырмаска - аның артыннан шатлык килә.

Фәнис Яруллинның "Җилкәннәр җилдә сынала" повестенда шундый өзек бар:

«Язмыш сезнең тез астына китереп сукса – егылмас өчен якасынаябышыгыз.

Утларга салса – үзегез аннан да көчлерәк янныгыз, шулвакыт кызуын сизмәссез.

Суларга ташласа , күбек булып өскә күтәрелмәгез, асылташ булып төпкә батыгыз, ялтыравыгызны күреп, чумып алырлар.

Тузан итеп һавага күтәрсә – яңгыр тамчыларына кушылып, җиргә төшегез.

Карурманнарда адаштырса – кояшка карап, юл сайлагыз.

Ташлар белән бастырса – чишмәгә әверелеп, ирекккә ургыгыз.

Җиргә күмсә – орлык шикелле тишеп чыгыгыз.

Җилкәннәрегезне җилләр екса – сөяегезне җилкән итеп күтәрегез.

Нинди генә очракта да җиңәргә өйрәнегез.

Көчле рухлылар гына максатка ирешә ала.

Түземлеләр генә бәхеткә лаек!»

Нинди искиткеч сүзләр! Мин дә шулай көчле рухлы булып яшәргә тырыштым.

Тормыш кечкенә генә нәрсәне дә зур итеп күрә белергә, һәр тапкан әйбернең кадерен белергә өйрәтте.

Балаларымда да яхшы сыйфатлар тәрбияләргә көч куйдым. Эшемдә дә сынатмадым. Күп тырышырга туры килде. Тормышымның үкенечле яклaрын күрмим. Аллаһы биргәнгә шөкер итәм.

Киләчәктә дә Раббыбыз биргән исәнлек белән, яраткан мәктәбемдә, яраткан коллективымда эшлисем, балаларга белем бирәсем, оныкларымны "Яктылык"ка китереп укытасым килә. Аллаһы шуларны насыйп итсен. Мәктәбебезгә тагын да зуррак юлларга чыгып, гөрләп, чәчәк атып эшләргә насыйп булсын.

Безгә алмашка яшь укытучылар да килә. Үзебезнең мәктәптән чыккан укучылар укытучы булып кайталар. Аларга да теләк телисем килә – йөрәкне биреп эшләгәндә генә, балалардан кеше ясап, үзеңне дә шәхес итеп күрсәтергә була. Үз-үзеңне мактамыйча, кеше читтән синең яхшы сыйфатларыңны күреп шатланса, бу инде тормышта – зур җиңү.

**– Фәния апа, Аллаһы Тәгалә сезгә ниятләрегезне тормышка ашырырга, мөгаллим хезмәтегезне әле озак еллар дәвам итәргә исәнлек, көчле рух, сабырлык бирсен.**

"Яктылык" мәктәбе мөдире **Радик Газизовтан** аның кул астында эшләүче Фәния ханым Гыйләҗева турында фикерен сорадым:

"Фәния ханым – олуг мактауга лаеклы шәхес. Үз эшенең остасы. Аның укучылары татар теле буенча олимпиадаларда катнашып, җиңү яулап киләләр. Бу инде – аның хезмәтенең яхшы күрсәткече. Бервакыт ул бер үк сыйныфларда татар һәм урыс телләре



*Фәния Гыйләҗеваның улы Руслан, килене Елена, оныклары*

дәресләрен алып барды. Ул укыткан балалар ике телдән дә югары уңышларга ирештеләр. Шулай Фәния ханым татар теленең рус телен үзләштерүгә берничек тә комачауламаганын профессиональ яктан дәлилләде. Методикалар эзләп тапты.

Фәния ханым укыткан балалар арасында медальгә баручылар да, бердәм дәүләт имтиханнарында 100 бал җыючылар да бар.

Ике баласы да "Яктылык"ны тәмамладылар. Хәзер кызының кызы да биредә белем ала.

Укучылар Фәния ханымны ярата-лар. Ул күп еллар сыйныф җитәкчесе булып тора. Быел менә бишенче сыйныфны үз канаты астына алды. Киләчәктә дә үзенә күркәм хезмәт күрсәтергә насыйп булсын".

Ә "Яктылык" мәктәбендә укутәрбия эшләре буенча директорның урынбасары, рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып хезмәт итүче **Фәридә Хәмидуллова** хезмәттәше турында болай диде:

"Эш буенча да, көндәлек тормышта да Фәния ханым белән аралашу күңелгә ятышлы. Ул – хезмәтен төгәл, тырышып башкаручы кеше. Аны нинди генә конкурста катнашырга чакырма, куркып тормый, эшкә алына да аны җиренә җиткереп башкара һәм лаеклы нәтиҗәләргә ирешә. Аның белән аралашып яшәгән кеше дә бер урында тапталып тормый. Фәния ханым үзе дә, максат куеп, эшен ахырына кадәр башкарып чыга һәм янындагы хезмәттәшләрен дә шуңа өнди. Без аның белән бергә сигез ел эшлибез инде. Мәктәптән тыш та, яхшы аралашабыз. Мавыгуларыбыз да туры килә. Диңгез, тауларга булган мәхәббәтебезне уртаклашабыз. Фәния ханым, укытучы буларак та, кеше буларак та, мактау сүзенә генә лаек».

Фәния апаның укучылары үзләренең укытучылары турында нәрсә әйтерләр икән, дип тә кызыксындым.

2013 елда мәктәпне тәмамлаган **Ләйсән Мансурова:**

"Фәния апа иң яхшы укытучыларның берсе булып күңелемә кереп калды. Минем һәм сыйныфташларым өчен ул икенче әни булды, дип тә әйтә алам. Фәния апа безнең сыйныф җитәкчебез иде. Ул һәрберебезне, үз баласыдай, кайгыртты. Укуда да, шәхси мәсьәләләребезне хәл итәргә дә булыша иде. Без һәрвакыт аңа мөрәҗәгать итә алдык.

Фәния апа – ярдәмчел, мәрхәмәтле, ачык, йомшак күңелле кеше, әмма таләпчән дә. Укытучы шундый булырга тиеш тә. Ул дәресләрен кызыклы итеп үткәрә. Аның ярдәмендә без ана телебез, татар әдәбияты, язучылар, шагыйрьләребез турында шулхәтле күп нәрсә белдек!

Мәктәпне тәмамлавыбызга сигез ел узды инде, ләкин без Фәния апабыз белән элемтәне өзмибез. "Яктылык"ка кунакка килгәч, ул безне елмаеп каршы ала, чәй белән сыйлый, хәл-әхвәлләребезне сораша. Ата-аналарыбыз турында да кызыксынырга онытмый. Исең китәр – ул бүген дә аларның барысының да исем-фамилияләрен исендә тота бит!

Мин Фәния апа Гыйләҗевага акыллы киңәшләре, безгә төпле белем биргәне өчен бик рәхмәтлемен".

Ә **Айгөл Нуретдинова** укытучысы турында түбәндәгеләрне сөйләде. Ул "Яктылык"ны 2015 елда тәмамлаган, хәзер туган мәктәбенә укытучы булып эшләргә кайткан:

"Фәния апаның дәресләре минем яраткан дәресләрем исемлегендә булды. Бигрәк тә татар әдәбиятын якын күрдем. Фәния ханым – олы йөрәкле кеше. Миңа аның белән бергә Казанга олимпиадаларга, конкурсларга барырга насыйп булды. Беренче баруда ук Фәния апаның кайгыртучан, илтифатлы булуын аңладым. Аның белән рәхәтләнеп көләргә дә, эчеңне бушатырга да була.

Хәзер Фәния апа Гыйләҗева белән бер коллективта эшләвемә шатланам. Аны күргән саен күңелем җылынып китә. Үзенә исәнлек-саулык, рәхмәтле укучылар укытып чыгарырга телим".




*Кызы Рания, кияве Илнар, оныклары*

# ШУГУРОВСКИЕ ГЕРОИ: САМАТ САДРИЕВ



***В последние годы (и месяцы) вхождения Бугульминского уезда в состав Самарской губернии село Старое Шугурово этого уезда стало местом рождения трех наших соплеменников, которые в середине 40-х стали Героями Советского Союза. Это Ибрагим Мурзин, Самат Садриев и Ислам Халиков. В их биографиях наряду с особенностями есть и схожие моменты: учеба в семилетней Старошугуровской школе, работа на Шугуровском битумном заводе, героизм на фронте в период Великой Отечественной войны. Первым из этих мужественных парней Золотую Звезду получил С.С. Садриев. С него и начнем повествование о шугуровских Героях.***

**Рашид ШАКИРОВ**

У Самата самый маленький самарский «стаж», составляющий всего около пяти месяцев. Герой нашей статьи родился 15 января 1920 года, а 27 мая по декрету ВЦИК была образована Автономная Татарская Советская Социалистическая Республика. Из Самарской губернии в ее состав передали 16 волостей Бугульминского уезда, в том числе Спиридоновскую волость, имевшую на своей территории село Старое Шугурово. Ныне оно находится в Лениногорском районе РТ.

Тем не менее факт наличия самарского начала биографии Садриева налицо, и это мы не будем забывать. Появился он в крестьянской семье Салаха абый и Ходзии апа (так указано имя в наградном листе сына-Героя), которая была не только численно большой, но, видимо, и крепкой в хозяйском смысле, поскольку есть упоминание о том, что Садриевым пришлось пережить раскулачивание. Если это на самом деле было так, то уже в школьниках Самату пришлось испытать первые трудности.



*В довоенной молодости*



*Актер шугуровского колхозного театра*

Любитель мальчишкой ходить в ночное, чтобы пасти лошадей, он с 15 (по другим источникам – с 13) лет начал посещать Шугуровский битумный завод, открытый в конце XIX века, где пилил дрова, за что получал дневной паек – 600 граммов хлеба. Дрова были важным элементом технологического процесса получения битума из добытого шахтным способом битуминозного песчаника. Его сгружали в огромные котлы с горячей водой и мешали большими деревянными ложками по 6–7 часов, пока битум, что легче воды, не всплывал на ее поверхность и позволял себя собрать.

По воспоминаниям старожилов, в окрестностях села Шугурово был глухой лес, и он весь пошел на топку для варки битума. Так что пилка дров была делом актуальным, и Самат, с детства проявлявший свое трудолюбие, терпеливость и смелость, с ней справлялся (хотя, по другим источникам, он был подкатчиком вагонеток с песчаником). Но в любом случае труд на этом заводе считался крайне тяжелым – неслучайно первые его рабочие были из числа ссыльных.

Наверное, поэтому Самат прервал свою карьеру пильщика-подкатчика и отправился летом 1936 года в Ярославль, где устроился учеником слесаря на хлопчатобумажное прядильное предприятие «Красный перевал», расположенное в Норском посаде. Потом в поисках своей профессии побывал в Перми и Самарканде. Затем вернулся на малую родину по-городскому одетым юно-

шей и в августе 1938 года устроился статистом Шугуровского районного отдела народного образования (по другим источникам – районного финансового отдела).

Спустя два года его пригласили выступать в Шугуровском колхозном театре. Самат тогда искренне считал, что нашел свое призвание, чем очень расстраивал отца. Труппа показывала в деревнях спектакли по пьесам татарских классиков, в которых нашему герою удавались роли сильных и волевых людей. Артистам довелось выступать и в Казани, на сцене драматического театра имени Галиаскара Камала. Но вскоре коллектив сельских поклонников Мельпомены распустили, и Садриев снова отправился в путь по стране.

Великая Отечественная война застала его с товарищем в г. Кутаиси. «Мы пошли в военкомат с просьбой направить нас на фронт. Но нам отказали, поезжайте, мол, на родину, там вас призовут быстрее», – вспоминал позже Самат эфенди. Поэтому в армию он пошел из родного села в начале февраля 1942 года.

Новобранца направили в Казань и на краткосрочных курсах в 23-м учебном танковом полку дали подготовку башенного стрелка. Причем полк тогда приступил к обучению танкистов, которым предстояло эксплуатировать иностранную технику, поскольку именно в феврале упомянутого года начались поставки в СССР американского среднего танка М3 Lee, более известного у нас как М3с («Эм три средний»), Кроме того, на вооружение Красной Армии поступил и американский М3л («Эм три легкий»).



*Бои во Львове, 1944 год*



*В последние дни войны*




*Колонна танков М3с под Курском, 1943 год*

В июле сержант Садриев оказался в действующей армии, а именно в 101-й танковой бригаде, в составе которой он вскоре принял боевое крещение. Бригада в тот период имела 50 танков, в том числе 30 М3с и 20 М3л. С начала 1943 года она вела бои на территории Курской области, и 16 марта, в ходе одного из сражений, Самат Салахович был ранен. Пришлось лечиться в госпитале в течение пяти месяцев.

После выписки из медицинского учреждения он был зачислен в 667-й стрелковый полк (сп) 218-й стрелковой дивизии (сд) 2-го формирования на должность командира стрелкового отделения. Судя по срокам, прибыл Самат в новую часть после совершения дивизией 300-километрового марша своим ходом по июльской и августовской жаре, при нехватке воды, а во время дождей – по распутице проселочных дорог. Переход длился с 25 июля по 14 августа 1943 года.

То есть дивизия успела принять участие в заключительном этапе Белгородско-Харьковской наступательной операции «Румянцев» и 17 августа своими передовыми 658-м и 667-м стрелковыми полками прорвала оборону противника северо-



*Фабрика «Красный перевал», Ярославль*



СОЮЗ СОВЕТСКИХ СОЦИАЛИСТИЧЕСКИХ РЕСПУБЛИК

ГЕРОЮ СОВЕТСКОГО СОЮЗА

Тов. Садриеву Самату Салаховичу

За Ваш геройский подвиг, проявленный при выполнении боевых заданий командования на фронте борьбы с немецкими захватчиками ПРЕЗИДИУМ ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР своим указом от 3 июня 1944 г. присвоил Вам звание ГЕРОЯ СОВЕТСКОГО СОЮЗА.

Председатель Президиума Верховного Совета СССР

Секретарь Президиума Верховного Совета СССР

Москва—Кремль, 8 марта 1948 г.

№ 5707

*Грамота Президиума ВС СССР*



СССР

Герою Советского Союза гвардии старшине Садриеву Самату Салаховичу

Приказами Верховного Главнокомандующего Маршала Советского Союза тов. СТАЛИНА от 2 мая 1945 г. № 359, от ... 1945 г. № 366, от 9 мая 1945 г. № 368 за отличные боевые действия при овладении столицей Германии—Берлином, городом Дрезден и за освобождение столицы Чехословакии—города Прага всему личному составу нашего соединения, в том числе и Вам, принимавшему активное участие в боях, ОБ'ЯВЛЕНА БЛАГОДАРНОСТЬ.

Командир части



Герою Советского Союза гвардии старшине Садриеву Самату Салаховичу

Приказом Верховного Главнокомандующего Маршала Советского Союза товарища СТАЛИНА от 2 мая 1945 года № 359 за полное овладение столицей Германии—городом БЕРЛИН — центром немецкого империализма и очагом немецкой агрессии всему личному составу нашего соединения, в том числе и Вам, принимавшему участие в боях, ОБ'ЯВЛЕНА БЛАГОДАРНОСТЬ.

Командир части

*Две благодарности ВГК*

западнее села Боромля, сумев через день освободить одноименную станцию. А с 27 августа по 6 сентября части и подразделения 218-й стрелковой дивизии вели упорные бои в направлении г. Зенькова Полтавской области. К 10 часам утра 18 сентября бойцы освободили пос. Ромодан той же области, являвшийся важным железнодорожным узлом. После этого дивизии было присвоено почетное наименование «Ромоданская».

Спустя четыре дня красноармейцы 218-й сд отбили у немцев еще один город Полтавщины (Золотоноша), и 23 сентября 667-й стрелковый полк, с боями заняв село Сушки, вышел к Днепру. Он получил приказ форсировать реку, отбросить противника от береговой полосы и создать плацдарм для форсирования водной преграды частями Красной Армии. Другим стрелковым полкам дивизии (658-му и 372-му) была поставлена задача блокирования гитлеровцев в полосе городов Золотоноша – Хорол.

Личный состав полка (566 чел.) начал готовиться к переправе. Сначала на правый берег Днепра ранним утром 24 сентября отправились 15 разведчиков и 10 партизан. Немцы проморгали их действия и позволили нашим преодолеть водную гладь. Но потом противник спохватился и выбил эту группу на левую сторону реки. Тогда в ночь на 25 сентября в дело была брошена специально сформированная группа захвата (60 чел., с пулеметами и минометами), которая к 3.00 форсировала Днепр и закрепилась, несмотря на противодействие фашистов. Видимо, в эту группу было включено и отделение сержанта Садриева.

Әлбәттә, кечкенәдән моңсәнгать эчендә кайнашып үскәнгә, Нурсәхи Йосыповка бөтен гомерен шуңа багышларга һәм бар булдыгын, яшәү көчен шуңа бирергә насыйп булгандыр да.

Нурсәхи Фатыйхович Лениногорск шәһәрендәге сәнгать-педагогика училищесын, аннан соң Казан дәүләт мәдәният институтын тәмамлый. Ул үзенең хезмәт юлын Камышлы район үзәгендәге Мәдәният Йортында инструктор-массовик буларак башлый.

Камышлы районындагы мәктәпләрдә музыка, рәсем, сызым дәресләрен укыта. Аннан соң Татарстанда мәдәният-сәнгать өлкәсендә эшли.

Тора-бара ул Бөгелмә районының Карабаш эшчеләр поселогында һәм Баулы шәһәрендә Мәдәният Йортлары директоры, Баулыда сәнгать-бизәү мастерское директоры, районның татар халык театры һәм "Нур" балалар театры студиясе җитәкчесе, аларның режиссеры була. Баулы районы администрациясенең мәдәният бүлеге мөдире булып та эшли. Ул Татарстанда танылган Фәйзулла Туишев исемендәге конкурс лауреаты була, Баулыдагы "Тальянка" исемле гармунчылар ансамбле җитәкчесе булып та эшли.

Кайда эшләсә дә, Нурсәхи Йосыпов үзен киңкырлы сәләт иясе, оста җитәкче итеп таныта. ВЦСПСның "Мәдәният профсоюзлары учреждениеләрендәге уңышлы хезмәте өчен", "Үзешчән халык иҗатындагы казанышлары өчен" күкрәк билгеләре, СССР Мәдәният министрлыгының Мактау грамоталары, Бөтенроссия фестивальләре һәм конкурслары лауреаты булып, медальләр һәм дипломнар белән бүләкләнә.

Ниһаять, аның хезмәтен югары бәяләп, аңа "Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре" исеме бирелә.







Нурсәхи Йосыпов тормыш иптәше итеп Иске Ярмәк авылында үзе укыткан иң чибәр, сәләтле кызны – Бадияне сайлый.

Хәлил кызы Бадия Мусина мәктәптә укыганда ук үзешчән сәнгатькә тартыла, һәм киләчәктә ул да үз гомерен тулысынча сәнгатькә багышлый.

Иртә тормышка чыгып, гаилә мәшәкатьләренә чумуына һәм өч бала анасы булуына карамастан, ике югары белем алып, Баулы районында төрле җитәкче урыннарда эшли.

Бадия Йосыпова Казан Дәүләт университетын, аннан соң Идел Буе Сәясәт институтының политология бүлеген, Казандагы марксизм-ленинизм университетында укып, аларны уңышлы тәмамлый.

Баулы районындагы мәгариф, мәдәният һәм сәнгать өлкәләрендә зур оештыру эшләре алып бара. Районның партия комитетында инструктор һәм идеология бүлеге җитәкчесе урынбасары, район администрациясенең мәдәният бүлеге мөдире, мәгариф бүлегендә инспектор, районадагы яшь туристлар станциясе директоры булып эшли.

Кайсы гына өлкәдә хезмәт итсә дә, кечкенәдән күңеленә якын булган сәхнә эшчәнлеген ташламый. Үз гомеренә ире белән бергә төрле кичәләр оештырып, концертларда, спектакльләрдә катнаша.

Аның да тырыш хезмәте һәм сәнгатьтәге уңышлары югары бәяләнә. “За трудовую доблесть”, “Ветеран труда” медальләре, “Мәгариф өлкәсендәге уңышлары өчен”, ВЦСПСның “Үзешчән сәнгатьтәге уңышлары өчен” дигән күкрәк билгеләре, күпсанлы рәхмәт хатлары, грамоталар, медальләр белән бүләкләнә, лауреат исемнәренә лаек була.

Кинофильмнарда, әдәби романнарда чын мәхәббәт турында күп языла һәм сурәтләнә. Тик тормыш ул күпкә катлаулырак. Аның сынаулары аша иң тирән, иң нечкә хисләреңне гомер буена тормыш сикәлтәләрендә түкми-чәчми саклап килү бар кешегә дә бирелми шул.

Нурсәхи һәм Бадия Йосыповларның олыгайган көннәрендә дә бер-берсен ихтирам итеп, тирән тойгыларын саклап яшәүләре гаҗәеп бер матур күренеш иде. Әлбәттә, мондый хәлнең ясалма рәвештә булуы һич тә мөмкин түгел.

Бадия Хәлиловна ире Нурсәхи Фатыйховичка сәнгать өлкәсендә югары нәтиҗәләргә ирешү өчен киң мөмкинлекләр тудыра. Ләкин дә иренең күләгәсендә генә булып, аның уңышларына юллар ачып кына калмыйча, әле үз урләрен дә яулый. Ул районда гына түгел, Татарстан һәм Рәсәй күләмендә үткәрелгән чараларда дан яулап, халык хөрмәтенә лаек була. Сәнгать өлкәсендәге казанышлары белән бергә, аның тыйнаклыгы, гадилеге һәм ягымлылыгы да – искитәрлек күренеш.

Сәнгатькә бирелгән кешеләр – хисләргә бай халык. Алар – ялкынлы йөрәкле һәм очкынлап янгандай яши торган халык. Тик андыйларның күбесе, үз өстенә өерелеп килгән дан-шөһрәт басымына түзә алмыйча, үзсенә. Ире дә, хатыны да сәнгатькә бирелгән күпчелек гаиләләрнең ныклы булмавы да сер түгел.

Ә менә Йосыповларның гаиләсендә бөтенләй башка хәл. Аларның, сокланырлык тормыш корып, бәхетле яшәүләре бик матур күренеш иде.

Нурсәхи һәм Бадия Йосыповлар үзләре сәләт иясе булганга, балалары да бай табигатьле, сәләтле шәхесләр булып үскәннәр.

Алар: “Эти-әниебезнең эшчәнлеге күп вакытта сәхнәдә булганга, безнең балачагыбызның да күп өлеше сәхнә артында үтә иде”, – дип искә алалар.









Яшьтән сәнгать осталары эшчәнлеген күреп үскәнгә, мәктәп елларында ук аларга да үз сәләтләрен үстерергә төрле мөмкинлекләр була. Алар сәнгать мәктәбен тәмамлыйлар. Өчесе дә, югары белем алып, үзләре сайлаган һөнәр буенча уңышлы эшлиләр.

Олы уллары Руслан, Мәскәү энергетика институтының Казан филиалын тәмамлап, Казандагы "Тасма" берләшмәсендә эшли. Аның гаиләсендә бер кызлары Диларә үсә. Хәзер инде ул үзе дә әни кеше – аның өч яшьлек кызы Даша үсеп килә.

Икенче уллары Ренат, мәктәпне алтын медальгә тәмамлагач, С. Орджоникидзе исемендәге Мәскәү авиация институтының "Отдел космонавтики и космичеких летательных аппаратов" бүлегендә укып, аны уңышлы тәмамлый. Аннан соң Екатеринбург шәһәрендәге Урал дәүләт университетының философия факультетында укый һәм, аспирантураны тәмамлагач, диссертация яклап, философия фәннәре кандидаты булуга ирешә. Хәзер ул – Октябрьск шәһәрендәге Уфа дәүләт нефть-техник университеты доценты.

Ренат ике бала үстерә. Кызы Светлана – Мәскәү Дәүләт университеты студенты һәм малае Артур – 11 класс укучысы. Боларда да әбибабаларыннан, эти-әниләреннән бирелгән сәләт ачык күренә.

Икесе дә сәнгать мәктәбенең музыка һәм художество бүлекләрен тәмамлаганнар. Шәһәр, республика һәм Рәсәй күләмендә үткәрелгән конкурсларда һәм олимпиадаларда катнашып, күп мәртәбә призёрлар һәм җиңүчеләр булып танылганнар. Аларның уңышлары турында газеталарда язылып, телетапшыруларда күрсәтелгән. Шулай ук фәнни эшләр алып баруда да алар кечкенәдән актив катнашканнар.

Нурсәхи һәм Бадия Йосыповларның кызлары Резедә – югары белемле юрист. Юриспруденция өлкәсендә ул башта Казан шәһәренең Идел Буе районындагы мировой судьялар канцеляриясе аппараты мөдире, аннан соң Баулыда шәһәр суды рәисенең ярдәмчесе һәм Баулы шәһәрендә мировой судья булып эшли. Ахырда үзенең шәхси оешмасын ача.

Резедәнең дә ике баласы үсә: кызы Диана – 6 класс укучысы һәм уллары Мансур – 2 класс укучысы. Диана сәнгать мәктәбенең художество бүлегендә укый, театр студиясендә, фольклор түгәрәгендә һәм волейбол секциясендә шөгыльләнә. Ул йөзү буенча разрядлы спортчы һәм аның рәсеме Мактау тактасыннан төшми.

Диана катнашкан театр коллективы Ленинград блокадасы турындагы спектакле белән регионнар арасында узган конкурста – Гран при, шулай ук Россия күләмендә узган фестивальдә икенче урынны яулый һәм Бөекбританиянең махсус призын алуга ирешә.

Кечкенә Мансур да спорт мәктәбенең футбол секциясендә шөгыльләнә һәм киләсе елга шулай ук сәнгать мәктәбенең художество бүлегенә укырга керергә хыяллана.

Татарстандагы Баулы шәһәрендә һәм аннан читтәге төбәкләрдә яшәсәләр дә, Нурсәхи һәм Бадия Йосыповларның балалары, оныклары да Бадия ханымның туган Иске Ярмәк авылы кешеләре белән тыгыз элемтәдә торалар һәм шулай ук үзләренең туганнары белән якыннан аралашып яшиләр.

Нурсәхи һәм Бадия Йосыповлар, "Ак каен" ансамбле оешканнан бирле аның үзешчәннәре белән һәрвакытта тыгыз бәйләнештә булып, ансамбль эшчәнлегенә төрле яклап ярдәм итеп килделәр. Шулай ук күп кенә бәйрәмнәрне, чараларны да бергә уздырдылар.

Мәсәлән, уллары Ренатның никах туен да авылда "Ак каен" ансамбле белән бергә авылның Мәдәният Сараенда, борынгыдан килгән туй йолаларын үтәп, матур бер фоль-

клор бәйрәме рәвешендә үткәрделәр.

Инде Нурсәхи Йосыпов бакыйлыкка күчкән булса да, Бадия ханым авыл белән бәйләнешен өзми, һәр яз башында авылга кайтып, туган йортында үзе оештырган музей эшчәнлеген дәвам итеп, аны төрлечә тулыландырып, җанландырып тора.

Шулай борынгыдан яшәп килгән ата-бабаларының да рухын үстереп, алар яшәгән заманнарда шаулап узган вакыйгаларны җанландырып, шуларны халыкка күрсәтү өстендә дә мавыгып эшли.

Бу музей, акрын гына авылның бер рухи үзәгенә әверелеп, күпләрне үзенә тартып тора. Бадия ханым җәй көннәрендә оныклары белән шунда яши. Бакча чәчеп, алар да авыл тормышын күреп, эшкә өйрәнеп үсәләр.

Үз нәселләренең истәлеген саклау исәбеннән төзи башлаган бу музей акрынлап колхоз чорын да тирәнрәк сурәтләүгә күчә. Чөнки Бадия ханымның әтисе озак еллар колхоз һәм авыл советы рәисе булып эшләде һәм ахыргача актив тормыш позициясендә торды.

Акрынлап борынгырак тормышны гәүдәләндергән материаллар да җыела торды.

Ниһаять, бу музейга авыл халкы, мәктәп укучылары һәм әле башка авыллардан да кунаклар, укучылар да килеп, милләтебез тарихы буенча сәяхәт ясап, рухларын үстереп, әхлак дәресе дә алып китәләр.

Иске Ярмәккә Баулы шәһәрендәге Бөтендөнья татар конгрессы бүлекчәсе җитәкчесе, "Ак калфак" оешмасы әгъзалары, андагы тарих музееның фәнни хезмәткәрләре дә килә. Алар музейда, авылдагы "Ак каен", "Ак калфак" оешмалары эшчәнлеге белән танышып, кунак булып, татар телен, мәдәниятен саклау һәм үстерү юлындагы проблемалар турында фикер алышып, матур очрашу оештырдылар.

Шулай ук Самар шәһәреннән этнографик экспедиция дә килеп, анда тупланган әйберләрне фотога төшереп, музей эшчәнлегенә югары бәя биреп китә.

Хәзер инде халыкка төрле ирекләкләр бирелде. Тик шулай да, татар теленә торган саен ныграк югалу куркынычы яный. Гореф-гадәтләребез дә сансызланып, аларга булган хөрмәт һаман да кими бара. Дөрес, моны һәм халыктагы милли үзаңны саклау, үстерү турында кайгыртучы өндәүләр еш яңгырый-яңгыравын.

Ә менә Йосыповлар династиясе вәкилләре кебек, үзләре үрнәгендә аны ничек итеп үстерү һәм саклап яшәү кирәклеген күрсәтеп, башкаларга да чын үрнәк булып, буыннан-буынга халкыбыздагы үҗәтлекне пропагандалап яшәүчеләр күпме соң?! Андыйлар булса да, бик аз санда шул...





# ФЕРМЕР САЛАВАТ ЗАЛЯЕВ:



Салават Заляев

# «СӨТЛЕБИКӘЛӘРЕМНЕ ӘЗ ГЕНӘ ДӘ КҮРМИ ТОРСАМ, ҮЗЛӘРЕН САГЫНЫП БЕТӘМ»

***Сыерларын яратып: «Сөтлебикә», дип кенә атап йөртә Яңа Ярмәк авылы фермеры Салават Заляев. "Без сөйләгәнне аңлыйлар алар, татарча өйрәнделәр инде", – дип шаярта да. Ә чынында бу шаярту да түгел икән бит. "Сыерларга тавышыңны күтәр әле син, аннары сауганда алар бер урында тормыйлар, тибенә башлыйлар. Мал да үзен яраткан кешене ярата шул", – ди кулга ияләшкән сыерларын сыйпап, иркәләп кенә торган фермер.***

**Миләүшә ГАЗИМОВА,**
*Җәмилә Шәрифуллина фотосурәтләре*

Заляевларның фермасы йортларыннан ике йөз метр ераклыкта урнашкан.

"Фермага иртән иртүк чыгып китеп, сәгать уннарда өйгә әйләнеп кайтам. Аннары кичке дүрткә яңадан анда барам. Шул арада инде малларымны юксынам. Үзләрен кочам да үбәм – шулкадәр нык сагындырыла!" – дип сөйли милләттәшебез.

Салават әфәнденең әтисе Мөдәррис 42 ел тракторчы булып эшләгән, әнисе Фәһимә 44 ел авыл фермасында сыер сауган. Дүрт баласы арасында төпчек булган улы Салават алтынчы сыйныфка күчкәч, әнисе аны көн саен кичләрен үзе белән фермага алып бара башлый. Сөт тулган чиләкләрне абзарның бер башыннан икенче башына ташырга ярдәм итә малай. Аннары әнисе аны сыер саварга да өйрәтә. Ә инде 7 – 8нче сыйныфларда укыганда, әти-әнисе берәр кая кунакка китсә, Салават фермада әнисе урынына сыер саварга да кала торган була. Әле бит ул вакытларда аппарат-фәлән юк, кулдан савалар иде. Мәктәп яшендәге малай 15 сыерны саусын әле!

Әнисе улын кечкенәдән сыерлар карарга, аларны көтүгә чыгарырга, печәнен әзерләргә дә өйрәтә.

**"Алайса төпчек бала иркә була, диләр. Сез бер дә иркәләнеп үскәнгә охшамагансыз. Әнә балачагыгызда олылар эшен булдыргансыз",** – дигәнемә Салават абый елмаеп куйды:

«Әйе, апаларым Резеда, Нурия, абыем Марат та син безнең кебек түгел, өлгер дә соң бит, диләр иде".

Салават әфәнде Себер якларында да эшли, Самарда түбә ябып та йөри.

Дүшәмбе авылдан Самарга эшкә чыгып китә һәм җомга көнне әйләнеп кайта торган була. Йорттагы малларын хатыны Асия карый тора. Өчәр сыер, үгезләр тоталар алар. Ит саталар. Ул вакытларда әле авылларда сөт җыеп йөриләр иде бит. Салават абый бер литр сөтне башта – өч, аннары биш сумга тапшырып җибәргән чакларны

хәтерли. Җәйгелеккә утызышар бройлер тавыгын сатып алалар, йөзәр чебеш үстерәләр Зәләевлар.

Авыл куенында, мал-туар, кошкорт карап, бакча үстереп, көтү көтеп үскән Салават абыйның күңеле туган җиренә, авыл хезмәтенә тартыла шул.

“Гомер буе колхозда эшләгән кешеләрнең баласы кем булсын инде? Тракторчы, фермер... Авыл җирләрендә крестьян-фермерлык хуҗалыкларын булдырырга ярдәм итүче яңа “Агростарп” программасы барлыкка килүен ишеткәч, анда катнашу турында озак уйланып йөрдем мин. Куркыбрак, шикләнебрәк тордык. Гаиләм дә башта бу идеяны хуплап бетермәде. Шарт буенча грант акчасының ун процентын үз акчаң тәшкил итәргә тиеш бит. Менә өч миллионлык грантның 2 миллион 636 меңен дәүләт бирде, ә 364 меңе – үземнеке. Безнең өчен бу – зур акча, әлбәттә. Шуңа күрә тәвәккәллек итмичә тордык. Аннары барыбер катнашырга җөрьәт иттек.

2019 елда, кирәкле документларны әзерләп, гариза бирдем һәм грант оттым. Беренче омтылыштан ук уңышка ирешүемә күпләр гаҗәпләнде”, – дип сөйли әңгәмәдәшем.

Үзенең тракторы искергән булганга, Салават абый грант акчасына терлек азыгын әзерләү өчен өр-яңа МТЗ-82 тракторы, печәнне җыеп пресслау һәм аны рулонга төрү җайланмасы, ә бер миллион сумга кара-чуар токымлы ун сыер сатып ала.

“Мал тоткан кешегә тракторсыз булмый – җир дә сөрә, печән дә чаба, җыя да, рулонга да төрә бит ул. Иртән тракторда чыгып китәм дә кичкә кадәр эшләп йөрим”, – ди Салават абый.

**“Ә ни өчен нәкъ сыерлар тотарга уйладыгыз соң?”** – дип кызыксындым аңардан.

“Сөттән файда күп килә. Сыер тоткач, акчаның һәр көнне кергәнен белеп торасың. Сөтен тапшырасың, каймагын, эремчеген, катыгын, маен ясап сатасың. Ә ит токымын бер ел ярым, бер ел да сигез айлар асрарга кирәк бит әле.

Бүгенге көндә безнең шул ун сыерыбыз һәм бозауларыбыз да бар, ягъни сөт токымын да, ит токымын да тотабыз, барлыгы – 24 баш.

Әлегә ун сыердан тәүлегенә 150 литр сөт савып алабыз. Бу аз инде. Сыерларыбыз беренчегә генә бозауладылар бит әле, шуңа күрә сөтләре әллә ни күп түгел. Былтыр без бер елга җиде йөз җитмеш өч мең сумлык табыш алдык. Икенчегә бозаулагач, сөтләре арта барачак. Менә ике сыерыбыз икенчегә бозаулады инде, хәзер өченчесен көтәбез. Бер сыердан елына биш-алты тонна сөт алу тиешле”, – дип уртаклашты милләттәшебез.

Сыерларны заманча чит ил аппараты белән хатыны Асия сава икән. Эремчеген, катыгын, каймагын да ул ясап сата.

“Сөтебез тәмле, сыйфатлы булгач, сатып алучыларга кытлык юк. Үзебезнең авыл халкы да, башка җирләрдән дә киләләр. Мактап, рәхмәтләр әйтеп китәләр. Эремчек, каймак-катыкка да сорау зур. Хәзер күп кешенең экологик яктан чиста, табигый ризыклар ашыйсы килә бит. Сөтне Исаклы районының Ганькино авылына илтеп тапшырабыз. Анда аена бер – ике тапкыр анализ алып торалар. Сөтебезнең майлылыгы – 3,9 процент”, – дип сүзгә кушылды Асия ханым.

Зәләевлар ике кешене рәсми рәвештә эшкә алганнар, хезмәткәрләре тулы социаль пакет белән тәэмин ителә.

“Үземнең күршеләрем алар – Марат Кадыйров һәм Булат Фәтхуллин. Сызгырсаң да, тәрәзәгә шакысаң да, койма аша кычкырып чакырсаң да, шунда ук килеп җитәләр. Киңәшеп эшлибез. Үзләренә “Афәрин!” – дип кенә әйтә алам. Рәхмәт яусын, уңайсыз хәлгә куйганнары юк”, – ди Салават әфәнде.

Хәләл җефетен, балаларын да мактап телгә ала ул:

“Хатыныма куанып бетә алмыйм, Аллаһыга шөкер. Уңган, эшчән, гел булышып тора. Ул 19 ел укытучы булып хезмәт итте, бүген китапханәдә эшли. Иртәнге сәгать биштә сыер саварга чыгып китәбез, тугызда әйләнеп кайтабыз да ул эшкә китә. 28 ел бергә гомер итәбез. Балаларым Алисә, Руслан да, шөкер, тәүфыйклы булып үстеләр. Кызым юридик белем алды, Самарда милек департаментына урнашты. Руслан нефть тармагын сайлап алды. Кряж бистәсендә “Роснефть” заводында эшли. Атна саен кайтып, ярдәм итеп торалар”.

Фермерның 110 гектар җире дә бар. Ул анда – бодай, күбрәк өлешенә арпа чәчә.

“Үзебезнең җир булу бик яхшы инде. Бодаен, арпасын, печәнен, саламын сатып ала башласаң, кыйммәткә төшә бит. Ә болай, әлһәмдүлилләһ, малларыбызны ашатырга җитеп тора. Бодаен авыл халкына да сатам. Бездә күбесенчә олы яшьтәге кешеләр яши, алар мөгезле эре терлек асрый алмыйлар. Кемдер тавык тота, кемдер җәйгелеккә каз, үрдәк сатып ала. Ә кошкорт күбрәк бодай ашый бит инде”, – ди фермер хуҗалыгы башлыгы.

**“Салават абый, ашату дигәннән. “Сыерның сөте – телендә”, дип юкка гына әйтмиләрдер инде. Малны, иң беренче чиратта, дөрес ризыкландырырга кирәк бит. Бу инде сөт күләмен дә арттырачак. Сез терлекне дөрес ашатыр өчен рацион төзисезме?”** – дигән соравыма ул болай дип җавап бирде:

“Үзебез гел бертөрле ризык белән тукланмыйбыз бит. Терлек да шулай инде. Аңа силосы да, печәне дә, фуражы да, саламы да – бөтенесе дә кирәк. Мәсәлән, маллар көндез – силос, төнгегә печән ашый. Алларында тозлары тора. Капчык-капчык витаминнар сатып алабыз, аларны фураж белән бутап бирәбез. Прививкаларын кадатып торабыз.

Урамда биш градустан артык салкын булмаса, үзләрен утарга чыгарабыз, анда да саламы да, печәне дә салынган, тозы да куелган. Син сыерларга бер генә көн суны вакытында эчермә әле, ике-өч сәгатькә генә соңарып бир, күзгә күренеп сөтләре



кими. Бөтенесе үзебездән тора. Малны ничек тәрбиялибез, нәтиҗәсе дә шундый булачак".

**"Сез – җир кешесе. Яз җиту белән, күңелегез кырга ашкынамы?"**

"Язын гына түгел, кышын да ашкына. Хәзер дә басуларга барып киләм. Җәйләрен инде иртән иртүк чыгып китәм дә шунда югалам. Маллар карарга да, кырда эшләргә дә яратам. Таң атканда басуда сайраган тургай тавышлары күңелемнең иң нечкә кылларын тибрәтеп җибәрәләр. Күңелемнең бер чите сөтлебикәләрем белән булса, икенчесе кыр-басуларда инде минем".

**"Игенче буларак, татар халкының: "Язгы бер көн ел туйдыра", дигән мәкален ничек аңлатыр идегез?"**

"Язын чәчү эшләрен вакытында, яхшы итеп, ныклап башкарып чыкмасаң, көзен кырда иген шауламаса, эскерт-эскерт салам-печән өелмәсә, сенаж-силос базлары тулмаса, фермаларда да күпләп ит-сөт җитештерә алмыйсың ул".

**"Крестьян-фермер хуҗалыкларын булдыру авылның үсешенә китерәме? Аны нидән күрәсез?"** – дип кызыксындым Салават абыйның фикере белән.

"Китерә генәме! Авылыбызда яшәүчеләрнең күбесенең җире бар, күпләп мал-туар тоталар. Мин яшьләргә дә: "Нигә сез грант алу программаларында катнашмыйсыз?" – дип әйтеп киләм. Үз акчабызга гына тиз арада сыерлар да, трактор да сатып алып булмый шул. Авылның берничә кешесенә генә булса да эш урынын булдыру да ни тора бит".

**"Киләчәктә хуҗалыгыгызны зурайтырга ниятлисезме?"**

"Уй-ниятләребез бик күп безнең. Сыер абзарларын сипләп, аларны зурайту, сыер башын йөзгә җиткерү, малларны ашату-эчерү өчен заманча җиһазлар алу турында да хыялланабыз. Әле менә яхшы токымлы сарыклар да алырга телибез. Үзебез өчен генә алты оя умартабыз да бар, кош-кортлар да тотабыз.

Авылда торгач, эшләп үскәч, хезмәттән курыкмыйбыз. Беркайчан да кулларны кесәгә тыгып, тик басып торганыбыз юк. Эшебез булганга куанып яшибез. Иң мөһиме – Аллаһы Тәгалә исәнлек бирсен. Тырышсаң, теләгең булса, барысын да булдырырга мөмкин", – дип шатланып сөйли Салават әфәнде.

Зәләевларның шулхәтле эшчән, уңган булуларына исләрем китте минем. Аларның йокы күргәннәре дә юктыр инде. Үзем авылда үскән кыз булгангадыр инде, Салават абыйны якын күрдем. Бигрәк тә ул ачык йөзле, аралашучан, гади, эчкерсез кеше булып чыкты, минем белән бар күңелен биреп сөйләште.

Яңа Ярмәктә гомер итүче **Гөлсинур** апа **Гафуровадан** авылдашы Салават Зәләев турында фикерен сорагач, ул да минем сүзләремне хуплады:

"Салават минем кызым Гөлшат белән бер сыйныфта укыды. Шулкадәр акыллы бала ул! Киң күңелле, ачык йөзле, кешелекле, миһербанлы. Шулай күпләп кар яуган көннәрнең берсендә ирем тыштан өйгә керде дә: "Салават тракторында урамнарны чистартып йөри. Үзенә кул болгаган гына идем, шунда ук килеп җитеп, капка төпләребезне кардан чистартып та китте", – дип сөйләде. Менә шундый ярдәмчел кеше инде ул Салаватыбыз. Күптән түгел мин аңардан бодай алырга бардым. Елмаеп, апа, апа, дип кенә тора. Бодаен да арттырып та сала әле.

Тәртипле гаиләдә тәрбияләнеп үсте, әти-әнисе дә бик яхшы, уңган кешеләр иде. Мин аның әнисе белән бергә сыер савучы булып эшләдем.

Салаватның хатыны да бик ипле, ачык йөзле, гел елмаеп тора. Китапханәгә баргач, шунда ук кирәккән китабын да табып бирә, хәлләрне дә сораша. Игелекле балалар инде, үзләре дә игелек күрсеннәр. Кеше белән талашып, ызгышып йөри торганнардан түгел. Раббыбыз үзләренә исәнлек бирә күрсен. Эшләре гөрләп барып, авыл халкын шулай куандырып яшәргә язсын".

Салават абыйга: **"Шушы авыр хезмәткә алынуыгызга үкенмисезме?"** – дигән соңгы соравымны биргәч, ул, бер дә икеләнмичә, болай дип җавап кайтарды:

"Нигә грант алу программасында алдарак катнашмадык икән, дип кенә үкенәбез. Барысыннан да канәгать, бәхетле без.

Әлеге программа буенча биш елга исәпләнгән килешүнең срогы беткәч, Аллаһы насыйп итсә, тагын дәүләт ярдәмен алыр өчен гариза бирергә планлаштырабыз".

Салават әфәнде Зәләев, башлап җибәргән хезмәтен ташламыйча, аны гомерлек эше итәргә тели. Димәк, базарларда чын авыл сөте дә сатылачак, авыл халкы эшле дә, Яңа Ярмәкнең киләчәге дә өметле булачак... Аллаһы Тәгалә чын авыл кешесе, чын җир кешесе булган Салават абыйга игелекле ниятләрен тормышка ашырырга насыйп итсен.





*Гаилә башлыгы – Мәҗит Мөниров*



*Гөлчирә ханым ышанычлы ярдәмчесе – улы Ильяс белән*



*Гөлчирә Мөнирова*

# ТАТАР БАЙТУГАНЫНЫҢ УҢДЫРЫШЛЫ ҖИРЕНДӘ ОҖМАХ ПОЧМАГЫН БУЛДЫРГАН МӨНИРОВЛАР

***“Урамда буран, кар ява, ә мин теплицама керәм дә кыштан җәйгә эләккән сыман булам. Тирә-юнемдәге яшеллек оҗмахның бер почмагын хәтерләтә. Дересен әйткәндә, күптәнге хыялым тормышка ашты бит минем”, – дип елмая сөенечен яшерә алмаган Гөлчирә апа Мөнирова.***

**Миләүшә ГАЗИМОВА,**
*Евгений Литвинов фотосурәтләре*

Татар Байтуганы авылында гомер итүче бу ханым, лаеклы ялга чыккач, крестьян-фермер хуҗалыгын җитәкләп, эшкуар хатын-кызга әйләнгән.

“Гаиләбез зур булгач, күпләп маллар да тоттык, бакча да чәчтек. Аннары ирем Мәҗит кечкенә теплица ясады. Башта үзебез өчен генә помидор, кыяр рассадалары үстереп, утырта идек, чәчкәләребез дә күп булды. Ирем теплицаны зурайта торды. Үзебездән арткан яшелчәләрне авылдашларыбыза тараттык, аннары саткалый да башладык. Кешеләр: “Безгә дә рассада үстереп бир әле”, – дип тә сорап килделәр. Лаеклы ялга чыккач, ирем белән бергәләп, моның белән иркенләп шөгыльләнергә тотындык», – дип сөйләп китте Гөлчирә апа.

Зур теплица булдырып, сатуга күпләп яшелчәләр үстерү турында Гөлчирә апа күптәннән хыялланып йөргән. Ә Гали авылында яшәүче дуcларына барып, анда инде күп еллар буена киң җәелгән һәм чәчәк аткан әлеге бизнес эшләрен үз күзләре белән күреп кайткач, шик-шөбһәләре җилгә очкан, һәм ул бу турыда ныклап уйлана башлаган.

Әйе, уңганлыгың, булдыклылыгың, ә иң мөһиме – теләгең бар икән, барысына да ирешеп буладыр шул. Милләттәшебез авыл җирләрендә крестьян-фермерлык хуҗалыкларын булдырырга ярдәм итүче яңа “Агростарп” программасы турында белгәч, анда катнашырга карар кыла. Беренче тапкыр әле 2019 елда ук гариза бирә ул. Әмма үтә алмый. Тик уңышсызлыкка очраган кыю хатын аптырап калмый, барлык кирәкле документларны яңадан җыя, бизнес-план төзи дә тагын бер мәртәбә бәхетен сынап карый. Һәм, зур шатлыгына, бу юлы проектын яклап чыга ала.

“Теләгең булса, иренмәсәң, эше дә, ярдәмчеләре дә табыла. Документлар җыя башлаганнан бирле безне авыл хуҗалыгы министрлыгы да, Камышлы районы администрациясе дә, “Самара – Арис” оешмасы да безне җитәкләп бардылар һәм бүген дә күз астында тоталар. Дәүләт ярдәменнән башка мондый эшне башлап җибәрә алмас идек”, – ди Гөлчирә ханым.

Шарт буенча грант акчасының ун процентын үз акчаң тәшкил итәргә тиеш. Шулай өч миллион сумлык грантның өч йөз меңе – Мөнировларның шәхси акчасы. Аны алар теплицага газ үткәрүгә, скважина бораулап, су кертергә кулланганнар.

700 квадрат метрлы теплицаны махсус бригада төзесә дә, бу эшкә Мөнировлар үз өлешләрен дә керткәннәр. Балалары белән оныклары кайтып булышкан. Мәҗит әфәнде җылытыла торган идәннәрне, ягу системасын үзе ясаган.

Әйе, әлеге хезмәт зур гаиләне бергә туплаган. Ә бит Мәҗит әфәнде башта бу идеяны хуплап бетермәгән.

"Бик авыр булганга, бу эшкә тотынырга шүрләбрәк торган идем шул. Яшебез дә бар бит инде", – ди бу турыда Мәҗит абый.

Хәзер ул монда җан-фәрманга, яратып эшли – үзе электрчы да, эретеп ябыштыручы да, слесарь да, төзүче дә.

Гаилә башлыгы теплица эшенә алынырга башта шикләнебрәк караса, кече уллары Ильяс исә моңа шатланып туя алмый. Моның сәбәбе дә гади икән – егет кечкенәдән үсемлекләргә гашыйк, балачагыннан җирдә казынып үсә. Аеруча чәчкәләрне ярата ул. Мәктәптә укыган чагында әтисе аңа кышкы оранжерея да ясап биргән. Малай шунда мәш килә торган булган.

Бүгенге көндә Ильяс Кинель авыл хуҗалыгы институтында агрономия факультетының өченче курсында укый.

"Хыялыбызның тормышка ашуына мин бик бәхетле. Үземне башка хезмәттә күз алдына да китерә алмыйм. Аллаһы теләсә, бу гомерлек эшем булыр, дип исәплим. Үсемлекләрнең чәчәк атуын, күзгә күренеп үзгәрүен, уңыш китерүен шатланып күзәтәм. Хезмәтемнең нәтиҗәләрен күрү күңелемә май булып ята", – дип хисләре белән уртаклаша булачак агроном.

"Ял көннәрендә Ильяс кайтып, безгә булыша. Авылдашларыбыз аның янына килеп, яшелчәчелек буенча киңәш сорыйлар. Кайберәүләре үсеп китмәгән гөлләрен, чәчкәләрен китерә. Улым һәрберсен җентекләп карап, аякка бастыра", – дип сүзгә кушыла Гөлчирә ханым.

Яңа теплицаның нигезен июль аенда салганнар, ә август ахырында ул әзер булган. Аны төзер өчен урыны да туры килгән бит әле. Мөнировлар өч ел элек күршедәге ташландык йортны сатып алып, аны карап, җирен чүп үләннәреннән чистартып торганнар. Өр-яңа теплицалары шунда урын алган да инде.

Биредә заманча җиһазлар кулланыла. Җылылык һәм газ генераторлары да чит илнеке икән. Суны тамчылап сугару җайланмасы да бар. Һава торышын контрольдә тотучы җайланма автомат рәвештә үсемлекләрне - корылыктан һәм туңудан, ә фитолампалар кояш яктысы җитешмәүчелектән саклый. Ә менә газны әле яңа гына кертә алганнар. Документлар белән озак чабарга туры килгән.

Киләчәктә ел әйләнәсе эшләячәк теплицада фермерлар бер мең төп кыяр, алты йөз төп помидор үстерергә ниятлиләр. Ә үзләренең иске теплицаларын чәчәкләр утырту өчен кулланырга телиләр.





"Уңышларыбызны кайда сатарбыз, дип кайгырмыйбыз. Яшелчәләребезне кибетләр дә, базарда эшләүчеләр дә алырга әзер. Моңа кадәр кечкенә теплицабызда үстереп килгән кыяр-помидорларыбызның да сатылмыйча торганы булмады. Сыйфаты яхшы булса, бер тапкыр алган кеше аннары тагын килә бит ул, дуслары, туганнары, күршеләренә дә хәбәр итә", – ди Мәҗит абый.

Теплицалары ике бүлектән тора икән. Берсе рассада өчен каралса, икенчесендә инде яшелчәләр утыртылачак.

"Эшебез башланды гына бит әле. Яңа елга бераз укроп, петрушка, яшел суган үстереп саттым. Кыяр, помидор рассадаларым да бар инде. Яхшылап җылыткач, аларны утыртырга калачак", – ди Гөлчирә ханым.

**"Яшелчәчелек серләренә ничек**

**төшендегез соң?"** – дип кызыксындым аңардан.

"Галидә яшәүче дусларым бар, дидем бит. Әле дә шул авылга йөреп, тәҗрибә туплап торабыз. Бездә шундый зур теплица районыбызга бер булса, анда аларның саны йөзләгән! Аннары соң интернеттан бик күп мәгълүмат алабыз. Ильяс белән кич утырганда, ул мине компьютерда эшләргә өйрәтә. Әйдә, улым, биопестицидларның, фунгицидларның нәрсә икәнен аңлатып бир әле миңа, дим. Махсус дәфтәр тотам, студент кыз кебек, шунда барысын да җентекләп язып барам".

**"Гөлчирә апа, яхшы сыйфатлы яшелчәләр үстерү өчен беренче шарт – туфрак, дилә. Бу шулаймы? Сез туфракны кайдан аласыз?"** – дип сорадым.

"Үзебезнең җирләр бик әйбәт безнең. Әле Үзбәкстанда яшәгәндә бер әбинең, Россиянең бер төбәгеннән китерелгән бәрәңге бүлбесеннән төшкән туфракны кулына алып: "Уңдырышлы туфрак – таяк тыксаң, чәчәк атачак", дигәнен ишеткән идем. Бу, чыннан да, шулай булып чыкты.

Маллар күп булгач, черемәбез дә җитәрлек. Кинель-Черкассыдан торф кына алып кайттык. Яшелчә утыртылачак җиргә шул торф белән черемәне кушып җибәрәбез", – дип сөйләде әңгәмәдәшем.

**"Ә ашламалар кулланырга җыенасызмы?"**

"Быел әле ашламаларсыз гына үстерәчәкбез. Җиребез ял иткән бит. Киләчәктә инде күз күрер. Һәрхәлдә, бәяләре югарырак булса да, биоашламалар гына кулланырга тырышачакбыз. Кешегә экологик яктан чиста, табигый ризыклар сатасы килә бит. Химия белән болай да дөнья тулган".

Орлыкларның да чит илдә җитештерелгәнен кулланалар икән. Аларны заказ буенча Голландия, Америка Кушма штатлары, Нидерландтан кайтаралар.




Мөнировлар өч кешене рәсми рәвештә эшкә алганнар. Ике хатын-кыз һәм бер ират күршеләрендә генә яшиләр ди.

Татар Байтуганы фермерларының теплицаларын карарга төрле җирләрдән кешеләр килә. Эшкә күптән түгел генә тотынсалар да, алардан инде берникадәр тәҗрибә дә туплап китәләр. Әйтик, Кинель-Черкассыдан килгән эшкуарларны Мөнировлар теплицасының поликарбонаттан булуы һәм чит илдә ясалган җылылык генераторлары кызыксындырган. "Без бу тармакта 30 ел эшлибез инде, әмма теплицаларыбызны полиэтилен пленка белән генә каплыйбыз", - диләр икән алар.

"Ә без иң баштан поликарбонаттан ясауны сорадык. Рассада үстерү бүлекчәсен эчтән полиэтилен пленка белән үзебез капладык. Түбәдә җәен җилләтү өчен махсус форточкалар да бар.

Пленканы 2 – 3 ел саен алмаштырып торырга кирәк. Зур теплица өчен бу, әлбәттә, бик күләмле, күп акча һәм вакыт таләп итә торган эш. Ә поликарбонат хәтта 20 ел да чыдарга мөмкин", – дип уртаклашты Гөлчирә апа.

Гомумән, Мөнировларның йортыннан кунак өзелми. Гәҗитәләрдән, телевидениедән журналистлар еш була. Әле менә күптән түгел Мәскәүдән дә килеп, фермерлар турында репортаж ясап киткәннәр.



*Ильяс кечкенәдән үсемлекләргә гашыйк*

Булдырган кеше һәрьяклап булдыра инде ул. Мәҗит әфәнде үз гомерендә машина йөртүче дә, эреп ябыштыручы да, механизатор да булып хезмәт иткән, кулыннан килмәгән эше юк икән.

Гөлчирә ханым социаль хезмәткәр булган. Россия Федерациясе буенча үз хезмәтендә иң яхшы эшче булып танылган.

Мөнировларның тормыш юлларына да исең китәр. Гөлчирә апа Үзбәкстанда туып-үскән. Үз вакытында тумышы белән Камышлы районыннан булган әбисе, балаларын ачлыктан коткарыйм дип, шунда барып урнашкан. 90нчы елларда Гөлчирә ханым әнисе белән бергә Байтуганга кайта. Бу вакытта аның ике баласы була инде. Биредә ул, хатыны үлеп, өч бала белән калган Мәҗит исемле ир белән танышып кушыла. Уртак малайлары Ильяс та дөньяга килә. Шулай итеп, Мөнировлар алты бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзер 12 оныкларына шатланып, 26 ел бергә гомер итәләр алар.

Ике кызлары – Рузия, Алисә – Усманда, ике уллары – Рәшит, Ринат Татарстанда яшиләр. Ә Тимурлары әтиәнисенең өйләре каршысында гына зур йорт салып кергән.

"Балаларыбыз, Аллаһыга шөкер, яхшы торалар, мул тормыш алып баралар. Бездән сорау түгел, киресенчә, рәхмәт яугыры, үзләре ярдәм итәләр әле", – дип сөенәләр нарасыйларының көнкүрешенә әти-әниләре.

Крестьян-фермер хуҗалыкларын булдыру авылның үсешенә китерәчәк, дигән фикердә Гөлчирә апа.

"Мин комиссия әгъзаларына да: "Улым агрономия факультетында белем ала. Аның авылда яшәп калуын телибез. Яшьләр бит, авылда эш юк, дип, шәһәргә кача торалар. Менә хәзер эш юк, дип әйтеп карасын!" – дидем".

Башлаган эшләрен ташламыйча, киләчәктә аны киңәйтергә хыяллаучы уңган-булган Мөнировлар гаиләсе бизнесының чәчәк атуына ышаныч зурдан. Бигрәк тә аларның эшен дәвам итә алырлык, ә иң мөһиме – моны үзе чын күңеленнән теләүче ышанычлы уллары Ильяс бар бит.



*Лотфулла һәм Халидә Насретдиновлар*

# АК ӘБИЛӘРЕБЕЗ – ТОРМЫШЫБЫЗНЫҢ БИЗӘГЕ

***Быел февральнең дүртендә 94 яшен тутырган Халидә әби янына юл тоткач, күңелемә шомлы уйлар да керде. "Йөзнең капкасын ачкан бит инде әби, ниндирәк хәлдә икән?" – дип, хафаланып та алдым. Ә инде фатирларының кыңгырау төймәсенә баскач, ишекне ачкан кызы Нәзилә янында ялтыравыклы матур күлмәген кигән, ак яулыгын бәйләгән, елмаеп басып торучы Халидә әбине күргәч, бик шатландым.***

**Миләүшә ГАЗИМОВА**

Аллаһыга шөкер, аяк өстендә, зиһене дә яхшы аның. Күзен каты чирләп алганнан соң, колаклары бик начар ишетсә дә, кызы Нәзилә апа ярдәмендә бер-беребезне аңлашып сөйләшә дә алдык әле.

Муллахмәт кызы Халидә Насретдинова Похвистнево районында урнашкан Гали авылында туып-үсә.

1945 елда Камышлы педагогия училищесын тәмамлап, туган авылына кайта ул һәм гомере буе башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшли.

Хәләл җефете – Оренбург өлкәсенең Йолдыз авылында туып-үскән Лотфулла белән дә нәкъ эшләгән вакытларында таныша.

Яшьләр хат язышып торалар. Ә инде 1950 елда мәхәббәт диңгезендә йөзгән егет белән кыз никах укыталар. Башта Гали авылында фатирда торып алалар, аннары йорт салып керәләр.

Лотфулла абый да – гомерлек укытучы. Физкультура, хезмәт дәресләрен укыткан, география, сызым, рәсем ясау буенча да белем биргән.

Өйләнешкәннән көннән Насретдиновлар гел бергә булалар, бер мәктәптә эшлиләр.

Ә 1978 елда алар, Яңа Куйбышев шәһәре янында урнашкан Южный бистәсендә йорт сатып алып, Гали авылыннан шунда күчеп урнашалар, күпләп мал-туар, кош-корт асрыйлар.

Тәртипле гаиләдә тәрбияләнеп үскән, дин юлыннан атлаган дәрәҗәле укытучыларның балалары нинди икән, дип уйлыйсыз? Әлбәттә инде, акыллы, тәүфыйклы, җәмгыятебезнең лаеклы уллары, кызлары булып үскәннәр алар.

1951 елда туган олы кызлары Сәгадәт күп еллар заводта эшләп, лаеклы ялга чыккан. Ул Яңа Куйбышев шәһәрендә гомер итә.



*Лотфулла бабай һәм Халидә әби кызлары Нәзилә белән*



*Тату гаилә табигать кочагында ял итә*



*Насретдиновларның яшь чаклары*

Ике кызы, өч оныгы бар.

Уллары Рөстәм Уфа шәһәрендә яши. Башкорт дәүләт университетында эшли, химия фәннәре докторы. Биредәге фәнни-тикшерү институтында җитәкчелек итә. 68 яшьлек Рөстәм әфәнденең кызы белән улы да - химия белгечләре икән. Әти-әниләренә җиде онык бүләк иткәннәр.

Төпчек кызлары Нәзилә апа, әти-әнисе эзеннән китеп, укытучы һөнәрен сайлаган. Кияүгә чыккач, Яңа Куйбышев шәһәрендә яшәп, башлангыч сыйныфларны укыткан, үз гомерендә балалар бакчасында тәрбияче, репетитор булып та эшләгән. Ике бала үстергән. Кызганычка, кызы Лилия яшьли якты дөньядан китеп барган шул. Ире Наилнең үлгәненә дә байтак еллар узган инде. Үз гомерендә күп кайгыхәсрәт кичергән Нәзилә апаның тормышында әнисе һәм улы Радик белән дүрт яшьлек оныгы Руслан иң зур бәхете һәм куанычы булып торалар.

Бүгенге көндә Халидә әби Самарга күчеп урнашкан кызы Нәзиләдә гомер итә дә инде. Гәрчә ул әти-әнисен әле Яңа Куйбышевта яшәгәндә үк үзе янына алып тәрбияли. Шул арада җиде ел да узып киткән. Лотфулла бабай гына октябрь аенда 93 яшендә вафат булган. Вирус эләктереп чирләгәннән соң, өзлеккән ул, авыруның нәтиҗәләре йөрәгенә бәргән.

"Әти-әниебез гомергә гел бергә булдылар. Әти әнине кулында күтәреп кенә йөртте. Бер-берсенә юл биреп яшәделәр. Бик яхшы, йомшак күңелле, ачык, ярдәмчел, миһербанлы кеше иде әти. Укучылары да, аларның ата-аналары да, кешеләр дә үзен бик яраттылар.

Йокы бүлмәсендәге бергә кушкан ике караватны әти үлгәч кенә, аерып куйдым. Хәтта авыраган ча-








*Лотфулла абый йорт-җирен барлый*


*Насретдиновларның балалары - Сәгадәт (сулдан уңга), Рөстәм, Нәзилә*

ларында да гел бергә яттылар алар, әтинең соңгы сулышына кадәр бер-берсеннән күз дә алмадылар.

Әнием, әлһәмдүлилләһ, терелде, әти генә шушы зәхмәттән котыла алмады шул. Икесе дә начар ишетсә дә, кара-каршы утырып, гөрләшәләр, бергә намаз укыйлар иде", - дип, күз яшьләрен сөртә-сөртә сөйли Нәзилә ханым.

Әйе, бер-берсен яратып-сөеп 70 ел бергә тату гомер кичергән хәләл җефетен югалтуны Халидә әби бик авыр кичергән.

Аның белән бергә альбом битләрен актарып утырганда да, ире сурәтләнгән һәрбер фотоны күргән саен, Халидә әби, моңсу күзләрен төбәп: "Менә минем бабам, җаныкаем", – дип әйтә торды.

Йөрәге тулы хәсрәт булса да, Халидә әби шаярып та ала, сөйләшкәндә берәр мәзәк кыстырып та җибәрә әле. Яшь чагыннан ук дини юлдан атлаучы бу әби, Аллаһы кушканча, сабыр булырга тырыша.

Гомумән, Халидә әбигә гашыйк булып кайттым мин. Аның балаларча самими елмаюын, нурлы күзләрен, ачык йөзен күрсәгез иде сез! Мине үз кызыдай якын күреп, бәбекәем, дип, әниемнекедәй йомшак куллары белән җилкәмнән сыйпап куйганда ул миңа үземнең газиз әбиемне хәтерләтте.

Лотфулла бабай белән Халидә әби – икесе дә хезмәт һәм сугыш ветераннары. Күпсанлы мактаунамәләргә, медальләргә лаек булганнар алар.

Халидә апа укыткан укучылары бүген дә шалтыратып, аның хәлен белеп торалар, күрешергә килеп,


*Лотфулла абый белән Халидә апа Южный бистәсендә яшәгән вакытларында*

рәхмәтләрен әйтеп китәләр икән.

Халидә әби биш вакыт намазын калдырмый. "Ясин" чыга, догалар укый. Лотфулла бабай да гел гыйбадәттә булган, дини һәм дөньяви китапларны күп укыган.

Уразаларын бозар өчен укытучыларга ыстаканнан су каптырып йөргән елларда да Насретдиновлар, качып-посып булса да, намаз укыганнар, ураза тотканнар.

Алар балаларына да дини орлыкларны салып калдыра алганнар. Нәзилә апа да, пенсиягә чыккач, намазга баскан. Яңа Куйбышев мәсҗиденә йөреп, дини белем алган. Әнисе белән бергә басып, гыйбадәт кылалар.

Нәзилә апаның әнисенә карата мөнәсәбәтен күргәч, күңелем изрәп китте. Ул аңа йомшак кына эндәшә, әни, нәрсә булса да кирәкме сиңа, дип сорап, үзен кочып-үбеп кенә тора. Шулай Лотфулла абый белән Халидә апа, тәүфыйклы нарасыйлар үстереп, үзләренә бәхетле картлыкка нигез салганнар.

Озак утырдым мин Халидә әби белән Нәзилә апа янында. Күңелемә шундый рәхәт булды. Кунакчыл, ачык йөзле Нәзилә апа да, ягымлы Халидә әби дә якын кешеләрем булып тоелды.

Халидә әби мине елмаеп, тагын кунакка кил, балам, дип, кул болгап озатып калды. Аллаһы Тәгалә насыйп итә күрсен. Саф күңелле, изге җанлы Халидә әбиебезнең 95 еллык олуг юбилеен билгеләп үтәргә язсын Раббыбыз. Ак әбиләребез – тормышыбызның бизәге бит алар...


*Бүгенге көндә Халидә әби кызы Нәзилә тәрбиясендә яши*



Мансур һәм Динә Шакировлар балалары белән

# “ХАТЫНЫ ИРЕН ЗУРЛАП, ХӨРМӘТЛӘП ЯШӘГӘН ГАИЛӘДӘ БӘХЕТ ТҮГӘРӘК БУЛА”

***Шәһәр буйлап матурдан-матур заманча мөселман күлмәкләрен кигән, яулыкларын төрле ысуллар белән бәйләгән туташ-ханымнарны күреп, берәүләр аларга гаҗәпләнебрәк караса, икенчеләре сокланып туя алмый.***
***Һәрхәлдә, тыйнак киенгән мөслимәләребез кып-кыска итәкләрдән, үтәкүренмәле күлмәкләрдән йөрүче хатын-кызлардан мең мәртәбә артык инде!***

**Миләүшә ГАЗИМОВА**

Самар Җәмигъ мәсҗидендәге мөселман кибетендә сату итүче 36 яшьлек Динә Салих кызы Шакирова – шундый күркәм хатын-кызларыбызның берсе.

Динә белән әңгәмә корып, тормыш юлы белән танышкач, аның эчке дөньясының байлыгына, татар хатыннарына хас тыйнаклыгына, уңганлыгына хозурландым. Әйе, хатын-кыз – ул тулы бер дөнья, аның күңеленә мәхәббәт тә, гүзәллек тә, йомшаклык та, иң көчле Ана хисләре дә, гаилә учагы җылысы да сыйган.

Көннең яктылыгы – кояшта, күкнең матурлыгы – йолдызларда, ә кешелекнең гүзәллеге – хатын-кызларда, дип юкка гына әйтмиләрдер инде.

**– Динә, син – Самарда туып-үскән кыз. Рус шәһәрендә яшәп, рус мәктәбендә укып, ничек шулхәтле яхшы итеп татарча сөйләшергә өйрәндең?**

– Гаиләдә бабай-әби, әти-әни безне татарча сөйләшергә өйрәтеп үстерделәр. Җәен, каникул вакытларында, безне әби-бабамның туган авылына – Иске Ибрайга җибәрәләр иде. Нәселебез зур безнең, туганнарыбыз күп. Ике-өчәр ай анда кунак булып, ана телен камилләштерә тордык.

**– Син – дини нәселдән. Әбибабаларың, әти-әниең, туганнарың – барысы да намаз укый. Сиңа беренче дини орлыкларны кайчан сала башладылар? Ничә яшеңдә намазга бастың?**

– Мин инде балачактан әтиәниемнең, әби-бабамның намаз укыганнарын, дога кылганнарын күреп үстем. Алар миңа кечкенәдән Ислам нигезләрен төшендерделәр, догалар өйрәттеләр.

Миңа 10 яшь тулгач, әнием якты дөньядан китеп барды. Әрвахлар өчен дога җан азыгы булып тора. Әнием мине ашата иде бит. Мин дә аның җанын ризыкландырырга тиеш, дип, аның рухына дога кыла башладым. Шулай әкрен генә намаз уку тәртипләрен өйрәнергә тотындым.

Вакыт үтеп, әтием өйләнде, икенче әнием дә намазда. Ул гыйбадәт кылгач, димәк, миңа да кирәк, дип, 16 яшьләремдә аңлы рәвештә намазга бастым.

**– Гыйбадәт кыла башлагач, тормышыңда нинди дә булса үзгәрешләр сиздеңме?**

– Намаз укыган кешегә тормышта җиңелрәк. Аллаһы Тәгалә ярдәмен биреп тора. Гомумән, намаз кешене начарлыктан тыя, тәртиптә тота.

Берәр нинди мәсьәләне хәл иткәндә нәрсә эшләргә белмичә, җавап эзләсәм, шикләнсәм, намаз укып, Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорыйм. Раббыбыз төшләрем аша минем соравыма җавап итеп берәр нинди билге җибәрергә мөмкин. Аны аңлап, дөрес юрый белергә дә кирәк.

Намаз укый башлагач, күңелемә тынычлык инде. Атлаган саен Раббымның ярдәмен тоям. Тормыштагы күп принципларым тагын да ныгый төште. Аллаһы Тәгаләгә шөкерана кылам. Иман байлыгы, исәнлек, дөрес юллардан гына йөрт, дип сорыйм.

**– Динә, 22 яшендә кияүгә чыккансың. Булачак хәләл җефетең Мансурның нинди сыйфатларын ошаттың?**

– Татар халкы гомер-гомергә, нәселенә карап, кызларын кияүгә биргән, улларын өйләндергән. Булачак иремнең дини нәселдән булуы күңелемә ятты. Акыллы, тыныч холыклы, гыйлемле, намазда булуы ошады. Хаҗ кылып та кайткан иде.

Мәхәббәт шулай ярала инде ул. Хәтта кыяфәтләребез белән дә охшаш без. Уйларыбыз да бер. Берәр нәрсәне аңлатып торырга да түгел, бер-беребезне күз карашыннан аңлыйбыз. Без, чыннан да, бер кошның пар канатыдай, бер-беребезгә туры киләбез.

Иремә 40 яшь, банк тармагында эшли. 13 ел бергә гомер итәбез.

**– Гаилә бәхетле булсын өчен ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр нинди булырга тиеш?**

– Динебез Ислам буенча гаиләдә ир – баш. Хатын-кыз аны ир итә белеп яшәргә тиеш. Безнең гаиләдә, Аллаһыга шөкер, нәкъ шулай. Табынга хәләл җефетем утырмыйча, балаларыбыз утырмый безнең. Аңардан башка кичке ашка тотынмыйбыз, эштән кайтуын көтеп торабыз. Нарасыйларыбыздан алдарак аны карыйм.

Һәрнәрсәдә хәләл җефетеңнең ризалыгын алу тиешле. Әйтик, үземә күлмәк, бизәнү әйберләре сатып алырга телим икән, башта иремнән моңа рөхсәт алам.

Аннары мөстәкыйль, көчле рухлы хатын-кызлар күп бит инде. Әмма бу сыйфатларыңны син иптәш кызларың, башкалар алдында күрсәт. Ә хәләл җефетең белән тыйнак, йомшак бул. Аның баш булуын үзенә сиздереп яшә.

Ир-ат – ул булдыручы, табучы. Ә хатын-кыз, өйне җыештырып, тәмле ризыклар пешереп, матур киенеп, елмаеп, ачык йөз белән ирен эштән каршы алырга тиеш.

Ир белән хатын арасында шундый мөнәсәбәтләр урнашкан икән, тормышлары бәхетле булачак.

Мин моны үз гаиләмдә дә күреп үстем. Әнием әтигә зур хөрмәт белән карады. Икенче әнием дә нәкъ шулай ук. Әтиебез эштән кайтмыйча, без кичке ашка да утырмадык.

**– Динә, өч бала үстерәсез. Аларга дини тәрбия бирәсезме?**

– Әйе. 12 яшьлек улыбыз Әмир мәдрәсәдә белем алды, гарәп телен өйрәнде. Аллаһыга шөкер, остазлары бик яхшы булды. Безгә карап, үз теләге белән намазга да баста, ураза тота. Хәзер төрек телен үзләштерергә тели. Иманлы бала ул безнең, дингә нык тартыла.

Икенче малаебыз Самирга 5 яшь кенә булса да, аңа да дин тәртипләрен сеңдерәбез. Җәен, Аллаһы насыйп итсә, мәдрәсәгә укырга бирергә телибез.

Кызыбыз Амаль өч яшендә генә булса да, дингә тартыла инде. Кызлар, малайларга караганда, тизрәк өлгерәләр бит. Әйтик, өйдә мәҗлес үткәрәбез икән, ул, безнең исенә төшергәнне көтеп тормыйча, яулыгын бәйләп куя.

Шуңа күрә мәҗлесләрне без күбрәк өйдә үткәрергә тырышабыз. Балаларыбыз тәртибен, табында кемне нинди урынга утыртырга кирәклеген белеп үссеннәр.

Барысын да ата-ана өйрәтергә тиеш. Үзебез дә бабай-әби, эти-әни үрнәгендә тәрбияләндек. Алар гомер буе өйдә мәҗлесләр үткәреп килделәр, безгә күп белем бирделәр.

**– Ирең белән үзең татарча бик яхшы сөйләшәсез. Ә балаларыгызга ана телен өйрәтәсезме соң?**

– Әйе, алар белән татарча гына сөйләшергә тырышабыз. Әмиребез "Яктылык" мәктәбендә белем ала. Анда бик әйбәт, көчле укытучылар укыта. Әлбәттә, бала татарча яхшы сөйләшсен өчен аның белән гел ана телендә сөйләшергә кирәк. Кулланмый торсаң, ул онытыла бит.

**– Нарасыйларыгызны тәрбияләүдә кем күбрәк катнаша – синме, иреңме?**

– Икебез дә бертигез катнашабыз. Ирем уку, дин юлына бастыру буенча күбрәк улларыбыз белән шөгыльләнсә, мин инде кызыбызны күздә тотам.

**– Тәүфыйклы, акыллы балалар тәрбияләүнең сере нидә?**

– Аларны яратырга кирәк.

Шул очракта балалар исән-сау да, акыл-



лы да, тәртипле дә булачак, яхшы укыячак та. Үзләренә мәхәббәтеңне күрсәтеп торырга кирәк. Яратудан бик күп нәрсә тора.

**– Динә – син югары зәвыклы ханым. Берсеннән-берсе матур мөселман күлмәкләрен киеп, яулык бәйләп йөрисең. Аларны сатып аласыңмы әллә тектерәсеңме?**

– Күп яшь кызлар кыска итәктән йөрергә ярата бит. 16 яшемдә намазга баскач, әлбәттә, миңа болай киенергә ярамаганлыгын аңладым. Шуннан бирле мин озын итәктән генә йөрим. Тегүчем бар. Ул минем өчен менә инде 20 ел махсус мөселман күлмәкләрен тегә, рәхмәт яусын үзенә. Мөселман күлмәкләрен генә түгел, хәтта туннарны да аңардан тектерәм. Киемнәр сатып алганым юк минем.

**– Димәк, синең күлмәкләрең эксклюзив.**

– Шулай. Модельләрен үзем уйлап табам, тукымаларны да сатып алам. Киемнәремнең башка берәүдә дә кабатланмаганын яратам мин. Хәзер кызыма да тектерәм.

Буем кечкенә булганга, сатып алган күлмәкләрне барыбер кыскартырга туры килер иде. Ә болай буй-сыныма туры китереп тегелгән киемнәр килешеп тора.

**– Рус шәһәрендә мөселманча киенеп йөргән хатын-кызларга еш кына кырын караш ташлыйлар. Үзеңдә моны сизгәнең юкмы? Күлмәкләреңдә үзеңне иркен, уңай хис итәсеңме, беренче мәлләрдә оялу булмадымы?**

– Бер дә оялмадым, киресенчә, мөселманнарның ничек итеп матур киенгәннәрен күрсеннәр дип, башымны горур тотып йөрим. Аллаһыга шөкер, бер кырын караш күргәнем дә, бер начар сүз ишеткәнем дә булмады. Үземне иркен, уңай хис итәм.

Фитнес-клубка йөрим. Анда спорт костюмын киям дә яулыгымны бәйләп куям. Берсе бер сүз әйтсен, берсе бер кырын караш ташласын.

Кешеләр мине гаепләр, дип курыкмыйм, Аллаһы Тәгаләдән генә куркам мин.

**– Бизәнергә яратасыңмы соң?**

– Һәрбер хатын-кыз бизәнергә яратадыр инде ул. Ирем ризалыгын бирде, шуңа күрә тынычлап бизәнеп йөрим.

**– Синеңчә, заманча татар хатын-кызы нинди булырга тиеш?**

– Акыллы, белемле, чистапөхтә киенгән булырга тиеш. Күп сөйләмәскә, күп күрмәскә. Бу сыйфатлар беркайчан да модадан чыкмаячак.

**– Хәзер күп хатын-кызлар машина йөртә. Син рульдәме?**

– Әйе, мин күптән рульдә инде. Балаларны йөртергә дә, үз эшләреңбелән чабарга да кирәк. Бизнеста та кайнагач, машинасыз һич тә булмый шул.

**– Ирецне, балаларыңны нинди татар ризыклары белән сыйлыйсың?**

– Токмач ашлары, өчпочмаклар пешерәм, бәлеш салам. Балаларым боларны яратып ашыйлар, үзләре дә миңа әзерләргә булышалар әле.

**– Синең буш вакытларың да калмыйдыр инде?**

– Буш вакытлар юк инде ул. Вакытымның күп өлеше балаларыма багышланган, укудан тыш, аларны төрле түгәрәкләргә дә, секцияләргә дә йөртергә кирәк бит әле.

**– Динә, син Самар Җәмигъ мәсҗидендә бабаң Хәйдәрҗан Сафиуллин тоткан мөселман кибетендә менә инде 17 ел сатучы булып эшлисең. Кешеләр күбрәк нәрсә белән кызыксына, нәрсә сатып ала?**

– Бабам кибетне күбесенчә китаплар сатар өчен ачкан иде. Шатлыгыбызга, кешеләрне нәкъ алар кызыксындыра да.

Сатып алучылар арасында яшьләрне күргәч, сөенеп туя алмыйм. Мәсәлән, яшь кызлар килеп, намаз уку тәртибе китапларын сорыйлар. Аларны актарып карагач: “Апа, без аңлап бетермибез”, – диләр.

Мин аларга: “Яхшы, кызлар, иртәгә намаз вакытына килегез, мин сезгә барысын да аңлатып бирермен”, – дим. Шулай алар әкрен генә намазга да баса, гарәп телен дә өйрәнә башлыйлар. Аннары карыйсың, тәртипле мөселман егетләрен табып, мине никах туйларына да чакыралар.

**– Сездә бик күп китаплар сатыла. Аларны кешегә йомык күз белән сатып булмый бит инде – эчтәлекләре буенча төрле сораулар яудырырга мөмкиннәр. Китапларның эчтәлеге белән башта үзең танышып чыгасыңмы?**

– Әйе, әлбәттә. Бездә бер мең китап бардыр. Алар белән танышып чыгам, кыскача эчтәлекләрен дәфтәргә язып барам. Кеше сорау бирсә, уңайсыз хәлдә калуым бар бит. Сатучы буларак, мин аларга җавап бирергә тиеш.

Китап – ул теория. Практика таләп ителә. Кеше белән сөйләшергә, аңлата белергә кирәк.

Безгә килгән яшьләрне кулдан ычкындырмаска тырышабыз. Кызыксынулары бар икән, аларны хупларга кирәк.

**– Әти-әниең кем булып эшлиләр?**

– Әтием бабам Хәйдәрҗан белән бергә 1994 елда мөселманнарны



җирләү оешмасын ачканнар иде. Әтием энем Хәйдәр белән бергә әле дә шул эш белән шөгыльләнә. Кәфеннәр, кирәкле инструментлар, кабер ташлары, рәшәткәләр белән тәэмин итәләр. Бары тик кабер казу һәм җирләү белән шөгыльләнмиләр.

Әнием дә – бизнес кешесе. Шәһәребезнең "Норд" базарында мөселман кибетен тота.

**– Энең Хәйдәр дә дин юлындамы?**

– Әйе. Үзе дә, хатыны Лиана да – намазчылар. Кечкенә кызлары бар.

**– Тормышта кемнәргә таянып яшисең?**

– Иң беренче, ирем Мансурга таянып яшим. Ул – минем саклаучым да, яклаучым да, киләчәккә өметем дә, яратканым да. Әби-бабам, әти-әнием дә – ышанычлы терәгем. Әнием белән кызларча серләшәбез инде. Бер сүз әйтмәсәң дә, ул барысын да үзе сизеп, күреп тора.

**– Дусларың күпме, алар да дини кешеләрме?**

– Дусларыбыз күп безнең. Мөселман кешеләре дә, руслар да бар. Мөнәсәбәтләребез һәрберсе белән яхшы. Руслар безнең хәләл ризык ашаганны, хәмер эчмәгәнне беләләр. Моны аңлап, яхшы кабул итәләр, мактыйлар да әле. Туган көннәрдә, бәйрәмнәрдә рәхәтләнеп безнең белән тәмле чәй эчеп, татар ашларыннан авыз итеп утыралар.



**– Кемнең акыллы киңәшләренә колак салып яшисең?**

– Әнием белән киңәшәм. Ул мине унбер яшемнән тәрбияләде. Аны "үги әни", дип атарга телем әйләнми. Ул – минем әнием. Үз кызыдай кабул итеп үстерде. Бер-беребезгә көненә бишәр-алтышар тапкыр шалтыратып торабыз. Мине кайгыртып яши. Иремә сөйләмәгәнне әниемә сөйлим мин. Аңа



рәхмәтләрем чиксез. Аллаһы Тәгалә үзенә исәнлек-саулык, озын гомер бирә күрсен.

**– Кемнән булса да үрнәк аласыңмы?**

– Бабам Хәйдәрҗан белән әбием Зәмзәмия безгә гомерлек үрнәк булып торалар. Динебез Исламга мәхәббәт тәрбияләделәр, кеше булырга өйрәттеләр, аларның акыллылыгына исләрең китәр, үзләренә мең-мең рәхмәт.

**– Бүгенге яшьләребезне ничек бәялисең?**

– Яшьләребезне яратам мин. Алар замана белән бергә атлыйлар, күп нәрсә белән кызыксыналар, күп беләләр. Миңа алар белән аралашырга кызык. Хәзер күп мөселман яшьләре дингә тартыла. Җомга намазларына йөрүчеләр арасында да, урта яшьтәге кешеләргә караганда, күбрәк картлар һәм яшьләрне күрәм.

**– Кешеләрдә нинди сыйфатларны якын күрәсең?**

– Мин кешеләрдә яхшы сыйфатларын гына күрергә тырышам. Гадел, намуслы, үз-үзләренә ышанган, максатчан шәхесләрне яратам. Куштанланучыларны, ялкауларны җенем сөйми. Күп сөйләмичә, гамәл кылучыларны ошатам.

